

# Самарские татары

Самар тата…

ЕЖЕКВАРТА… …ИХ ТАТАР

ВЫПУСКАЕТСЯ С 2012 ГОДА

№ 2 (47), АПРЕЛЬ–ИЮНЬ 2025



РОДНИК ФОЛЬКЛОРА СБЕРЕГАЯ



ГОМЕРЕ БУЕ ҺӨНӘРЕНӘ ТУГРЫ КАЛГАН



НА ВОЛНАХ СУДЬБЫ



ИМАНЛЫ ҺӘМ ТӨПЛЕ ИР-АТ УЛ!

## «Дерзкий в боях татарин» с позывным «Русский»

6+



# ООО «АКТАШ» предлагает услуги по правовой защите граждан и организаций



## ОКАЗЫВАЕМЫЕ УСЛУГИ:

- Юридическая помощь физическим лицам
- Юридическое абонентское обслуживание компаний
- Представительство в арбитражных судах и судах общей юрисдикции
- Услуги в области взыскания задолженности



За дополнительной информацией обращаться по телефону

**8 (927) 797-82-80**

либо по адресу: г. Самара, проспект Кирова, д. 206.

На правах рекламы

# Хөрмәтле дуслар!

Сезнең игътибарыгызга журналыбызның быелгы икенче, җәйге, санын тәкъдим итәргә шатмын. Гадәттәгечә, без аның битләрендә төбәгебез һәм илебез татарлары тормышында соңгы өч айда булып узган әһәмиятле вакыйгалар, кызыклы шәхесләр турындагы язмаларны, башка халыкларның тарихы һәм мәдәнияте белән таныштыручы мәкаләләрне урнаштырдык, татар телен һәм милли үзаңны саклауның никадәр мөһим булуына тагын бер мәртәбә басым ясадык.

Яз һәм җәй башы вакыйгаларга бай иде, шуңа күрә язарлык нәрсәләр дә күп булды. "Самар татарлары"ның бу санында сез шәһәребездә узган Сабан туе, үсешләрендә үзенчәлекләр булган балалар һәм аларның әти-әниләре өчен беренче тапкыр үткәрелгән Корбан бәйрәме турында укый алачаксыз. Озак тәнәфестән соң өлкә "Бердәмлек" татар газетасы редакциясе Струков бакчасында оештырылган матбугат фестивалендә катнашты. Бу турыда да укып белерсез.

Быел Иске Ярмәк авылының танылган "Ак каен" фольклор ансамбле 55 еллык юбилеен бәйрәм итә. Әлеге коллектив һәм аның алыштыргысыз җитәкчесе турында да зур язма урнаштырдык.

Шуны исегезгә төшереп үтәм, безнең журнал 2012 елдан бирле чыгып килә. Басылган барлык саннар да, оцифровкаланып, Tatmagazine.ru сайтында урнаштырылып баралар. Биредә үк укучыларыбыз татар авторларының Самарда дөнья күргән китаплары белән таныша алалар.

Бергә булыйк!



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*"Самар татарлары" журналының баш мөхәррире*

РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович –** президент СОТО «Туган тел»; председатель правления НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», член Общественной палаты г.о. Самара

**Хазиев Артур Ахатович –** председатель Центра Стратегических Исследований «Платформа XXI»

**Сайфиев Данияр Ирекович –** гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»)

**Нуретдинова Римма Равильевна –** главный редактор сайта samtatnews.ru

**Вакказов Расих Ахметшамилович** имам-хатыб мечети «Булгарское наследие»

**Ибятова Ляйсян Замиловна –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Надиров Азат Камилович –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Сафин Иршат Халилович –** старший имам-хатыб Соборной мечети г. Самары

**Хузин Ривгат Туктарович –** председатель комиссии Общественного совета при ГУ МВД России по Самарской области

**Мифтахов Искандер Фуадович –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Рамазанова Гюзяль Ибрагимовна –** директор СОТО «Туган тел»

**Юсупов Рамиль Закрриевич –** член Совета СОТО «Туган тел»

**Юсупов Фагим Ханифович –** член Совета СОТО «Туган тел»

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфоломеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Салахова Лилия Акрямовна**
**Ширязданов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**

# Уважаемые друзья!

Рад представить вашему вниманию второй в этом году, летний, выпуск нашего журнала. Как всегда, в нем мы постарались рассказать нашим читателям обо всех ярких событиях, которые произошли в татарской жизни нашего региона и страны за предыдущие три месяца, рассказать об интересных людях, познакомить с историей татар и культурой других народов, еще раз напомнить о важности сохранения родного татарского языка и своей национальной идентичности.

Весна и начало лета были насыщенными, а, значит, и поводов для публикаций было предостаточно. На страницах этого номера «Самарских татар» вы можете прочитать о том, как самарцы отпраздновали традиционный летний праздник Сабантуй, как впервые в столице нашей области прошел праздник Курбан-байрам для детей с особенностями развития и их родителей. Впервые за долгие годы редакция нашей татарской газеты «Бердэмлек» приняла участие в фестивале прессы в Струковском саду. О том, как это было, вы тоже узнаете из нашего издания.

В этом году свой 55-летний юбилей будет отмечать прославленный фольклорный ансамбль из села Старое Ермаково «Ак каен». Этому коллективу и его бессменному руководителю мы посвятили большой очерк, который, я думаю, тоже многих заинтересует...

Напомню, что наш журнал издается с 2012 года. Все изданные номера оцифрованы и размещены на сайте журнала: Tatmagazine.ru. Здесь же читатели смогут ознакомиться с книгами татарских авторов, изданных в Самаре. Будьте с нами!

# Содержание:


Сабантуй – праздник культуры и единства ........ 6
Массакүләм мәгълүмат чаралары бергә җыелды ........ 8
Аллаһы кодрәтенә ышаныч баглыйк ........ 10
Дәһшәтле еллар хатирәсе ........ 14
На волнах судьбы ........ 18
«Дерзкий в боях татарин» с позывным «Русский» ........ 23
Рәхәт булса да торган җир, сагындыра туган ил ........ 30
Бәхетле картлык ........ 31
Гомере буе һөнәренә тугры калган ........ 33
Отцовский повторяя путь ........ 45
Булгары против монголов ........ 53
Разбойники, бандиты и неблагородные пираты ........ 55
Иманлы һәм төпле ир-ат ул! ........ 60
«У меня была своя цель»: самарец Шамиль Гимаев стал абсолютным чемпионом Европы в пауэрспорте ........ 63
Гомер таулары биек ........ 64
Почему пользователи сети перестают писать на татарском ........ 66
Родник фольклора сберегая ........ 71
Развиваем искусство слова ........ 84
Древние праздничные традиции ........ 87
Этнические названия через века и страны ........ 91





57 «АРТЫБЫЗДАН ДОГА КЫЛУЧЫ, ИМАНЛЫ БАЛАЛАР КАЛДЫРАБЫЗ. ШУҢАРДАН ДА ЗУР ШАТЛЫК БАРМЫ СОҢ?!»





36 ПАЛАДИН МЕДИЦИНЫ И НЕОБЪЯТНОЙ ДОБРОТЫ





69 “ӘБИЕМНЕҢ АЛТЫНГА ТИҢ ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТЛӘРЕНҮТӘП ЯШӘРГӘ ТЫРЫШАМ”





80 «ОЧЕНЬ ХОЧЕТСЯ СПАТЬ И ПОБОЛЬШЕ КОНЦЕРТОВ»


## Уважаемые друзья!

*Приобрести журнал «Самар татарлары» можно по следующим адресам:*

- Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»)
- Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),
- Самара, ул. Стара Загора, 54 (в магазине внутри Соборной мечети).

**Стоимость текущего номера с доставкой – 300 рублей, стоимость номеров за 2024 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей.**

**Доставка журналов по Самаре – тел.: 8-937-64-044-77.**


Издатель «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28

**Главный редактор:** САЙФИЕВ Данияр Ирекович
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль ГАЛИМОВ, Рашид ШАКИРОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Аняс МИНГАЛЕЕВ
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Вадим ОЛЕНИН

**Адрес редакции:** 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28
**Телефон редакции:** 8-917-104-44-45
**Электронная почта:** samartatarlary@bk.ru
**www.samtatnews.ru**

**Журнал «Самар татарлары»** («Самарские татары»), № 2 (47), апрель–июнь, 2025
**Учредитель:** «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 15 июля 2025 г.
Тираж 1000 экз. Цена свободная

# ПУТИН ПЕТЕРБУРГ ФОРУМЫНДА: КАЗАННЫҢ СОҢГЫ ЕЛЛАРДАГЫ ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАБЫЗ

*«Татар-информ»*

Россия Президенты Владимир Путин XXVIII Петербург халыкара икътисади форумының пленар утырышы башланыр алдыннан Казан һәм Татарстан турында фикер алышты. Видеоны Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясе хәбәрчесе Павел Зарубин урнаштырган. Әлеге видеоязмага ТР Рәисе матбугат хезмәте җитәкчесе Лилия Галимова игътибар итте.

Республика турында сөйләшү Россия лидерының Петербург икътисади форумында Бәхрәйн делегациясе җитәкчесе Шәех Нассер ибн Хәмәд Әл-Халифа – әлеге дәүләтнең короленең улы белән очрашуы барышында кузгалган. Әңгәмәдә шулай ук форумның пленар утырышы модераторы, Sky News Arabia телеканалы генераль директоры Надим Котеич катнашкан. Ул 2024 елда Казанда узган БРИКС саммитына килүе турында сөйләгән.

«Шәһәр яхшы хәлдә, без Казанның соңгы еллардагы үзгәрешләре белән горурланабыз», – дип җавап биргән журналист сүзләренә Путин.

«Гомумән, Татарстан һәм Казан – төрле мәдәниятләр, төрле диннәр вәкилләре арасындагы аралашуның һәм яхшы үсешнең бик яхшы мисаллары», - дип дәвам итте ул Котеич сүзләреннән соң. Россиянең ни дәрәҗәдә алга киткән ил булуын һәркем үз күзләре белән күреп инанырга тиеш, диде ул.

«Әгәр игътибар итсәгез, анда православие чиркәүләре белән мәчетләр янәшә тора. Кешеләр бер-берсенә кунакка йөри. Бер-берсенең бәйрәмнәрен уртак бәйрәм итеп билгеләп үтә», - дип өстәде РФ Президенты.

«Петербург халыкара икътисади форумы пленар утырышы башланырга берничә минут кала Владимир Путин нәрсә турында сөйләдеме? Татарстан турында!» - дип шәрехләде бу видеоны Лилия Галимова.






# НА ПМЭФ ДОГОВОРИЛИСЬ О СОЗДАНИИ В РТ ПЕРВОЙ В РФ БИРЖИ ИСЛАМСКОГО БАНКИНГА

*Tatar-inform.ru*

На XXVIII Петербургском международном экономическом форуме (ПМЭФ) удалось заключить соглашение о создании первого в России специализированного отделения партнерских финансовых инструментов на бирже. Об этом сообщает пресс-служба Минэкономики РТ.

Соглашение по обеспечению долгосрочного, эффективного и взаимовыгодного сотрудничества в сфере партнерского финансирования подписали Министерство экономики Татарстана, акционерное общество «Биржа «ЦТС» и потребительское общество «Ас Салям». Совместная работа начнется с организации первой в стране биржевой площадки партнерских инструментов денежного рынка.

Запуск новой площадки позволит профессиональному сообществу получить доступ к сектору денежного рынка через удобный и прозрачный интерфейс, а также предоставит инструменты управления кассовыми разрывами и рисками. Новые возможности станут основой для привлечения долгосрочных инвестиций. Проект призван укрепить доверие инвесторов, минимизировать риски технических дефолтов и создать благоприятную среду для участников рынка партнерских финансов в сфере формирования ликвидности.

# САМАРСКИЙ СУД ОШТРАФОВАЛ ОРГАНИЗАТОРА КОЛЛЕКТИВНОГО НАМАЗА НА УЛИЦЕ

*islamnews.ru*

В Самаре суд оштрафовал руководителя местного общества мусульман для проведение коллективного намаза в непредназначенном для этого месте, сообщает МК-Самара. Сумма штрафа не уточняется.

Проверку по факту молитвы на улице около молельного дома в поселке Механзавод Красноглинского района областного центра начали месяц назад, после того как снятое местными жителями видео с молящимися распространилось в социальных сетях. Многие тогда высказали недовольство тем, что верующие занимают общественное пространство, что препятствует передвижению граждан.



Проверкой занималось следственное Управление СК РФ по Самарской области. Ранее во Владивостоке был оштрафован водитель городского автобуса за намаз на проезжей части.

# КАЗАННЫҢ «ЧЕРЕК КҮЛ» ПАРКЫНДА ШАГЫЙРЬ МУСА ҖӘЛИЛНЕ ИСКӘ АЛДЫЛАР

***Tatar-inform.ru***

22 июнь көнне Казанның «Черек күл» паркында Бөек Ватан сугышы башланган көнгә һәм шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә багышланган «Моабит дәфтәрләре» музыкаль-шигъри перформансы тәкъдим ителде. Перформанс Казан мэриясе тарафыннан Парклар һәм скверлар дирекциясе белән берлектә оештырылган.

Спектакль татар шагыйре лирикасын, автор музыкасын, биюне, вокал һәм драманы берләштерә.

«Черек күл» амфитеатры сәхнәсендә биючеләр - Марат Казиханов, Екатерина Дьяконова, Солтан Садриев, Олег Мельников, Лия Гыйсмәтуллова, Камал һәм Кариев театры артистлары, Казан консерваториясен тәмамлаучылар, Yummy Music Band төркеме чыгыш ясады.

Спектакльдә татар шагыйренең «Кошчык», «Хуш, акыллым», «Ялык», «Ышанма!» һәм башка шигырьләре кулланылды.



# РОССИЙСКИЙ ПАТРИАРХ НАЗВАЛ ПРОВОКАЦИЕЙ ПРИЗЫВЫ К БОРЬБЕ С МУСУЛЬМАНАМИ



***Патриарх Кирилл резко осудил провокационные призывы к конфликту с мусульманами.***

***mk.ru***

Патриарх Московский и всея Руси Кирилл назвал провокацией призывы к борьбе с российскими мусульманами под предлогом защиты русской культуры и Церкви. Об этом он заявил на собрании духовенства Калининградской митрополии. Стенограмма его выступления опубликована на сайте РПЦ.

Глава Русской православной церкви призвал «гнать прочь» тех, кто сеет рознь между православными и мусульманами, подчеркнув, что у обеих религий сегодня общая цель – забота о Родине. «Добрые отношения между конфессиями – важный фактор единства народа», – отметил патриарх.

Поводом для заявления стал вопрос настоятеля калининградского храма протоиерея Владимира Максимова о резонансных высказываниях схиигумена Гавриила (Виноградова), бывшего начальника Сочинского подворья Валаамского монастыря. Тот в своих проповедях допускал негативные высказывания в адрес мусульман и других религий, что вызвало широкий общественный резонанс.

5 июня его освободили от должности, а монастырь потребовал удалить аккаунты в соцсетях и прекратить публичную деятельность от его имени.

Патриарх Кирилл резко осудил подобные действия, назвав их провокацией. «Когда православные и мусульмане вместе с оружием в руках защищают страну… в такое время разжигать конфликт могут либо безумцы, либо люди со злыми намерениями», – заявил он.

Предстоятель РПЦ подчеркнул, что Россия демонстрирует уникальный пример мирного сосуществования православия и ислама, где верующие разных конфессий совместно отстаивают интересы страны. Он призвал сохранять межрелигиозное согласие, которое является залогом стабильности и единства российского общества.

# ФАДН РОССИИ ЗАВЕРШАЕТ РАБОТУ ПО РАЗРАБОТКЕ ПРОЕКТА СТРАТЕГИИ ГОСУДАРСТВЕННОЙ НАЦИОНАЛЬНОЙ ПОЛИТИКИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ НА ПЕРИОД ДО 2036 ГОДА

***samddn.ru***

Срок действующей Стратегии заканчивается в этом году. Впервые в проекте Стратегии значительное внимание уделено сохранению и развитию культуры русского народа как государствообразующего.

Выделен также отдельный блок задач, направленный на сохранение и развитие русского языка как государственного языка Российской Федерации и языка межнационального общения. В то же время в проекте сохранена преемственность и непрерывность основных положений действующей Стратегии, доказавших свою эффективность.

В проекте Стратегии сделан акцент на укреплении единства многонационального народа нашей страны при сохранении этнокультурного и языкового многообразия. Это отвечает вызовам времени. Сегодня сплоченность народа и межнациональное согласие являются главной всепобеждающей силой.

Усилена региональная составляющая реализации государственной национальной политики, что значительно повышает уровень ответственности регионов за обеспечение стабильности межнациональных отношений.

В проекте Стратегии учтен фактор влияния миграции на сферу межнациональных отношений, уделено внимание адаптации иностранных граждан к условиям жизни в российском обществе. Вместе с тем весь блок вопросов миграционной политики найдет отражение в Концепции миграционной политики, разрабатываемой в настоящее время МВД России. В этом году Концепция миграционной политики на период 2019-2025 годы завершает срок действия.

# «ВКУСНО – И ТОЧКА» ПЕРЕХОДИТ НА СТАНДАРТ ХАЛЯЛЬ

*islamnews.ru*

Сеть ресторанов быстрого питания «Вкусно – и точка» решила пойти на встречу верующим и разработать постное и халяльное меню для своих заведений. Об этом сообщил ТАСС генеральный директор компании Олег Пароев в кулуарах Петербургского международного экономического форума. Он подчеркнул, что пищевые предпочтения клиентов важны для компании, и она готова удовлетворить их запросы.

«Есть потребительская группа тех, кому важен халяль, есть те, кому важны постные продукты. И те, и другие потребители для нас абсолютно одинаково ценны. Мы стараемся удовлетворить по возможности все потребности. Работаем мы и над тем, и над другим, естественно», – сказал он.

Пришедшая на смену McDonald’s «Вкусно – и точка» сейчас является ведущей сетью предприятий быстрого питания в России, она представлена в 65 регионах страны и насчитывает более 930 предприятий общественного питания.




## ОПРОС: 44 % ЖИТЕЛЕЙ САМАРЫ ПОДДЕРЖИВАЮТ ЗАПРЕТ СОЦИАЛЬНЫХ СЕТЕЙ ДЛЯ ПОДРОСТКОВ

*Sova.info*

Согласно опросу, 44 % самарцев готовы поддержать подобный запрет в России. Они отмечают, что в соцсетях можно встретить нежелательных людей и что подростки слишком много времени проводят в них вместо учебы.

Против такой идеи высказались 34 % респондентов, указывая на бесполезность подобных ограничений и риск тайного использования, что усложнит контроль.

Некоторые считают, что общение в соцсетях важно, и запрещать его до 15 лет неправильно.

При этом среди молодежи до 35 лет поддержку идеи выражают 37 %, а среди более старших самарцев – 51 %. Среди родителей детей в возрасте от 7 до 15 лет – 54 %, следует из результатов исследования сервиса SuperJob.




# ИМЕННАЯ ПРЕМИЯ ГУБЕРНАТОРА САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ

17 июня в Самаре наградили лауреатов именной премии губернатора для одаренных детей и подростков. Лауреатом именной премии Губернатора Самарской области в номинации «Социально значимая деятельность» стала активистка первичного отделения «Движения первых» Шенталинской школы № 1 Галимова Вилия.

Мероприятие проводится более 20 лет и направлено на поощрение обучающихся, добившихся значительных результатов в реализации социально значимых проектов, ставших победителями олимпиад, спортивных состязаний, победителями и лауреатами конкурсов интеллектуальной, технической и художественной направленностей.

Поздравляем Вилию и желаем дальнейших успехов и побед!




# В САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ НАГРАДИЛИ ЛУЧШИХ МЕДИЦИНСКИХ РАБОТНИКОВ

*sota63.ru*

В понедельник, 9 июня, в Самаре в Самарском академическом театре оперы и балета имени Д.Д. Шостаковича прошло торжественное мероприятие, посвященное предстоящему Дню медицинского работника. Губернатор Вячеслав Федорищев поздравил медицинских работников с профессиональным праздником и вручил лучшим сотрудникам медучреждений региона региональные награды.

Губернатор вручил награды лучшим представителям отрасли. Почетный знак Нестора Постникова получил Мукатдяс Садыков, профессор кафедры ортопедической стоматологии Самарского государственного медицинского университета. Танзиля Шигапова – заведующий перинатальным центром – врач, акушер-гинеколог Похвистневской центральной районной больницы удостоена почетного звания «Заслуженный работник здравоохранения Самарской области».



# САБАНТУЙ ПРАЗДНИК КУЛЬТУРЫ И ЕДИНСТВА

***21 июня в Самаре в парке им. Гагарина состоялся областной татарский праздник Сабантуй. В этом году он проходит 36-й раз и приурочен к 80-летию Победы в Великой Отечественной войне и Году защитника Отечества. Праздник, который показывает богатую татарскую культуру, объединяет людей и поколения, представителей разных национальностей и вероисповеданий, собравшихся, чтобы отдать дань уважения национальным традициям.***

***Samddn.ru***





На празднике присутствовали почетные гости: первый вице-губернатор Самарской области Александр Фетисов, главный федеральный инспектор по Самарской области Михаил Феоктистов, глава г. о. Самара Иван Носков, председатель РДУМСО, муфтий Талип хазрат Яруллин, Герой России – пилот, который спас пассажиров посадив самолет в кукурузном поле, Дамир Юсупов, участник СВО, кавалер двух орденов Мужества Рамис Терегулов и другие.

Александр Фетисов зачитал приветствие губернатора Самарской области Вячеслава Федорищева, в котором было отмечено: «Сабантуй – это символ многогранной татарской культуры, праздник, объединяющий поколения и передающий национальные традиции. Желаю вам крепкого здоровья, счастья, благополучия. Пусть в каждом доме царит мир и гармония!». Он вручил награды активистам Самарской областной татарской национально-культурной автономии.



В знак поддержки и солидарности с теми, кто защищает интересы страны, на празднике была передана техника в зону проведения СВО – 11 автомобилей и 4 мотоцикла. Гуманитарную помощь оказали общественники, волонтеры, спонсоры. На мероприятии работала площадка по плетению маскировочных сетей и изготовлению окопных свечей, которые тоже будут переданы в зону боевых действий.

По традиции в самарском Сабантуе принимали участие гости из Татарстана. В этом году свои подворья представил Черемшанский район, порадовав гостей декоративным творчеством и ремеслами, национальными блюдами.



Одним из основных мероприятий Сабантуя по традиции стала борьба на поясах көрәш. Все желающие могли принять участие в спортивных состязаниях по перетягиванию каната, боях с мешками на бревне, лазанию на столбе, беге с ведрами на коромыслах, разбивании горшков с завязанными глазами, поднятии гири, армрестлинге и других.



«Татарский национальный праздник с тысячелетней историей Сабантуй – яркий пример открытости, гостеприимства, единодушия и сплоченности, этики и ценностей татарского народа. Если раньше он означал окончание весенних полевых работ и отмечался только татарами, то теперь он действительно стал общим для всех жителей России, нашего региона и города. Приятно, что вместе с нами его празднуют все самарцы!» – сказал исполнительный директор Самарской областной татарской национально-культурной автономии Руслан Мустафин.

В рамках культурной программы праздника на главной сцене Сабантуя выступили вокальные и хореографические фольклорные коллективы, состоялся дизайнерский показ от бренда «SAF» и традиционных костюмов татарской и мусульманской моды «Аселя ханым» от женского сообщества «ВоблаGO Женщин». Работала выставка-продажа блюд татарской кухни.

Семья Аминовых каждый год принимает участие в Сабантуе, младшее поколение выступает на сцене, а родители и бабушки встречаются с родными и друзьями, смотрят концерт и посещают ярмарку. «Сабантуй самый веселый и многолюдный праздник, в нем душа нашего народа, он показывает традиции и всех объединяет», – поделился впечатлениями глава семьи.







Сабантуй – это не просто веселье, игры и национальные костюмы. Это живая связь между поколениями, символ дружбы и единства, который особенно ценен в сегодняшние непростые времена. Праздник в Самаре стал ярким подтверждением того, что все народы могут жить в гармонии, чтить свои корни и вместе строить будущее.



# МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫ БЕРГӘ ЖЫЕЛДЫ

## Самарда XXX «Матбугат-2025» фестивале узды

***7 июньдә Самарның Струков бакчасында төбәк басма мәгълүмат чаралары һәм телекомпанияләренең юбилей фестивале узды. Ул Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына һәм Ватанны саклаучылар елына багышланган иде. Чараны Россия Журналистлар берлегенең Самар өлкә бүлеге һәм Самар шәһәр округы администрациясе оештырып килә.***

*Эльмира Сәйфуллина*

Фестивальдә төбәкнең танылган басмалары һәм телекомпанияләре, шулай ук студентлар матбугат чаралары катнашты - барлыгы 20 мәйданчык эшләп торды.

Матбугат хезмәткәрләре белән очрашуга килгән шәһәр халкы өчен бай программа әзерләнгән иде: Росгвардия идарәсе тынлы оркестры, музыка һәм бию коллективлары чыгышлары, мастер-класслар, конкурслар, тематик викториналар, солдат боткасы әзерләп торган кыр кухнясы һәм башка күңелле чаралар. Теләге булган тамашачы «Покров 63» берләшмәсе волонтерлары белән бергә маскировка челтәрен үрергә өйрәнде. Шулай ук «Я рисую Победу» конкурсында катнаштылар, җиңүче балаларны кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләделәр.



Фестивальне ачу тантанасында сәламләү сүзе белән Россия Журналистлар берлегенең өлкә бүлеге рәисе, Россиянең атказанган журналисты Ирина Цветкова чыгыш ясады. Шәһәр башлыгы Иван Носков та журналистларга, матбугат эшенә катнашы булган һәр кешегә рәхмәтләрен белдерде. «Безнең тормыш турында дөресен сөйләгән, эшен яраткан, үз сүзләре һәм гамәлләре өчен җавап бирергә әзер булган журналистларга рәхмәт. Гомумән, шушы матур бәйрәм өчен дә рәхмәт. 30 ел буе үткәрелеп килгән чара күптән инде матур традициягә әверелгән. Димәк, аның 50 еллыгы да, 100 еллыгы да булачак әле», - дип сөйләде мэр.

Тантаналы өлештән соң интерактив мәйданчыкларда актив эш башланды.

Безнең газета өчен бу фестивальдә катнашу традициягә иярү генә түгел, чарага килгән кунакларны милли басмабыз белән таныштыру һәм укучылар белән




очрашу мөмкинлеге дә булды. «Бердәмлек» өлкә татар иҗтимагый-сәяси газетасы һәм «Самар татарлары» журналы мәйданчыгына җыелган кунаклар өчен гармунчы-виртуоз Мидхәт Әминов җитәкчелегендәге «Идел» татар эстрадасы ансамбле, Римма Шлыгина-Шәймиева җитәкчелегендәге «Заман» балалар фольклор ансамбле чыгыш ясадылар.

Араларында төрле милләт вәкилләре булган тамашачылар татар җырларын рәхәтләнеп тыңладылар, сугыш көйләрен көйләделәр һәм бию көенә типтереп биеделәр. Дәртле музыка яңгыраган мәйданчык яныннан бу көнне өйләнешкән пар да тыныч кына узып китә алмады. Кияү белән кәләш, безнең күңел ачуларга кушылып, татар биюенең берничә хәрәкәтен үзләштерделәр. Ә мәйданчыгыбызда җыелган кешеләр аларны чын күңелдән котладылар.

Руфия Биккулова һәм Рәхимә Хәйрова үткәргән милли стильдәге брошкалар ясау буенча мастер-класста катнашырга теләүчеләр дә бик күп булды. Бу көнне безнең мәйданчыкка килүчеләр газета редакциясе хезмәткәрләре белән таныштылар, басманың киләчәге һәм татар телен саклауның мөһимлеге турында видео-сораштыруда катнаштылар. Теләге булган һәркем бу көнне газетабызга язылa алды.



Утызынчы Матбугат фестивалендә беренче тапкыр «Губернаның алтын каләме» конкурсы һәм губернатор призларына журналистлар конкурсы җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды. Фестиваль нәтиҗәләре буенча «Бердәмлек» газетасы «Пресса-2025» фестивале дипломына лаек булды!

Мәйданчыкны оештыруда ярдәм иткән даими иганәчеләребез - Ильяс Гомәр улы Шәкүровка, Ригил Фәрит улы Курмаевка һәм Рузил Идрис улы Бурангуловка чиксез рәхмәтләребезне белдерәбез. Шулай ук «Яктылык» мәктәбенең актив әниләренә һәм балаларына да, бәйрәм рухы тудырып, милли киемнәр һәм бизәнү әйберләрен, татар массакүләм мәгълүмат чараларын лаеклы тәкъдим итәргә булышканнары өчен, рәхмәтебезне юллыйбыз!





# АЛЛАҺЫ КОДРӘТЕНӘ ЫШАНЫЧ БАГЛЫЙК




## Самарда инвалид бала тәрбияләүче гаиләләр өчен махсус Корбан гаете узды

***Менә инде берничә ел Самар мөселманнарының төп бәйрәмнәре - Ураза һәм Корбан гаетләре, иртәнге бәйрәм намазлары корбан чалу һәм сый-нигъмәтләр ашау белән генә чикләнми, балалар өчен кызыклы һәм тәрбияви чаралар да уздырылып килә. Ә менә үзенчәлекләре булган балаларны тәрбияләүче гаиләләр өчен Корбан бәйрәме региональ Диния нәзарәте тарафыннан быел беренче тапкыр үткәрелде.***

***Данияр Сәйфиев***

Бәйрәм хисе Җәмигъ мәчетенең төп мәйданчыгына якынлашканда ук сизелә иде. Балаларны, әтөп кунаклар нәкъ менә алар иде, аниматорлар уен-көлке, кабартылган чәчәкләр белән каршы алалар, балаларга тапшыралар. Колга аяктагы (ходули) клоуннар балаларны әледән-әле кулларына күтәреп алалар һәм, бергә фотога төшеп, кабат җиргә бастыралар. Читкәрәк куелган өстәл янында шау-шу һәм гаугa хөкем сөрә – бирәдә рәсем, кул эшләнмәләре ясарга һәм, төрле матур ябыштыргычлар кулланып, үз кулларың белән матур открыткалар эшләп чыгарырга була. Күбесе аквагрим остасына чират торалар – ул балаларның яңакларына махсус буяулар белән чәчәкләр һәм башка бизәкләр төшерә. Виртуаль чынбарлык күзлекләре дә үзенчәлекле балаларда зур кызыксыну уята, чөнки шулай гына алар су асты дөньясына әләгә алалар. Ә көчен һәм җитезлеген күрсәтергә теләгән балалар Самар өлкәсе буенча адаптив тхэквондо федерациясе җитәкчесе Нуриддин Пазылов оештырган спорт мәйданчыгында кайнашалар. Әлбәттә, бер генә катнашучы да аннан бүләксез китми.



Бәйрәмне «Нур» мәдрәсәсе ректоры Али хәзрәт Сөләйманов ачып җибәрде. Ул җыелган ата-аналарны һәм балаларны Корбан гаете һәм Зөлхиҗҗә ае белән котлады, гаиләләренә сәламәтлек, киләчәккә ышаныч теләде, инвалид баласы булган гаиләләргә зур игътибар һәм шатлык бүләк иткән өчен әлеге бәйрәмне оештыручыларга һәм волонтерларга рәхмәт белдерде.

Ә мондый игътибар, чыннан да, бу категория гаиләләр өчен бик мөһим. Чөнки авыру балаларның үзләренең генә түгел, аларның гаилә әгъзаларының да тормышы чикләнгән, мондый балалар янында даими рәвештә кемдер булырга тиеш. Аларны караучының башка эшкә вакыты да, көче дә калмый. Гаиләнең финанс ягы да чикләнгән: баланы дәвалау һәм тернәкләндерү арзан түгел. Һәм, кагыйдә буларак, бөтен авырлыклар әниләр җилкәсенә төшә: мондый гаиләләрнең күбесе тулы түгел. «Көчле җенес» дип аталган ир кеше, авыру бала туу һәм инвалидлык белән очрашкач, еш кына гаиләсен ташлап китә, әнисе шундый зур бәла белән үзе генә көрәшергә тиеш була. Шулай булгач, чынында кем көчле җенес икән, дип уйга каласың.





Әлеге чара инициаторы һәм оештыручысы Алсу Зилидинова сүзләренә караганда, мондый бәйрәмне уздыру идеясе аның күңелендә күптән туган.

– Бервакыт минем янга бер инвалид баланың әнисе килде һәм Җәмигъ мәчете гади балалар өчен бәйрәмнәр һәм төрле чаралар үткәрә, ә менә авыру бала белән килү мөмкин түгел, дип зарланды. Менә шул вакытта мин ният иттем – үзенчәлекле гаиләләр өчен аерым бәйрәм уздырачакмын. Шулай, балаларга шатлык бүләк итәсе, әниләренә бу дөньяда үзләре генә түгел икәнлеген күрсәтәсе, Аллаһы Тәгаләнең аеруча яраткан кешеләренә сынаулар биргәнен исләренә төшерәсе килде. Мин үз идеямне мөфти Талип хәзрәткә җиткердем һәм ул, һәрвакыттагыча, башлангычымны хуплады. Бу бәйрәмне планлаштырганда мин гаиләләр, социаль ярдәм үзәкләре һәм инвалидларның иҗтимагый оешмалары белән күп аралаштым, бу балаларга ничек якынаерга, үзләрен нәрсә белән сөендерергә һәм ничек зыян китермәскә икәнлеген өйрәндем. Әкренләп командабыз формалашты һәм бергәләшеп бу идеяне тормышка ашыра алдык.




Мин Нуриддин Пазыловка, Алеся Шәмсетдинова-Варнаевага һәм Дилфүзә Әсәновага, үзенчәлекле балалар язмышына битараф калмыйча, күңелләрен биреп эшкә алынганнары өчен чиксез рәхмәтлемен. Зур һәм бердәм волонтерлар армиясенә һәм, безнең проект турында ишеткәч үк, берсүзсез бөтен кирәкле ярдәмне күрсәткән иганәчеләргә дә зур рәхмәт, алардан башка берни дә барып чыкмас иде. Ниятең ихлас булганда, Аллаһы Тәгалә бөтен ишекләрне дә ача, – дип сөйләде әзерлек барышы турында Алсу Зилидинова.

Ә бәйрәм, чыннан да, бик якты һәм бай булды. Балалар Аллаһы Тәгаләгә ышану, табыну, басынкылык һәм рух көче турында куелган «Предопределение» спектаклен карадылар (аны Казан кунагы - Рузана Хөснетдинова тәкъдим итте), сабын куыклары тамашасында чыр-чу килеп катнаштылар, иганәчеләрдән алган бүләкләргә һәм программа ахырында тәкъдим ителгән тәмле ризыкларга чын күңелдән шатландылар. Шул ук вакытта ата-аналарга һәм оештыручыларга бераз күңелсез дә булды. Беренче чиратта, бик зур теләк булса да, ниндидер могҗиза белән бу балаларга савыгырга ярдәм итә алмау һәм моны эшләү мөмкин түгеллеген аңлаудан. Аның каравы, Алсу Зилидинова, аның командасы оештырган онытылмаслык бәйрәм бүләк итәргә дә мөмкин бит аларга! Аллаһы Тәгалә кодрәтенә ышаныгыз, моны аңлау да күпне тора.



# АЛДА ӘЛЕ КҮПМЕ ЮБИЛЕЙЛАР КӨТӘЧӘК!..



***«Җомга көн, уенче» җитте исә, хорафатларга ышанучылар аны кыенлыклар һәм күңелсезлекләр белән бәйләр иде. Кошки районының Орловка авылы халкы өчен, киресенчә, мондый җомга бик тә шатлыклы үтте. Беренчедән, җомга - мөселманнар өчен үзеннән-үзе бәйрәм, икенчедән, Россия көне уңаеннан дүрт көнлек озын ял көннәре дәвамы, өченчедән, һәм бу, мөгаен, иң мөһимедер, Орловка халкы 10 еллыгын тутырган мәчетләренең беренче юбилеен билгеләп үтте.***

***Данияр Сәйфиев***

Бу авыл мәчете зур түгел. Орловка совет елларында бөтен илгә шаулаган «Дружба» нәсел заводының үзәк утары булган, һәм бүген дә бу авыл исеме өлкә халкы теленнән төшми, чөнки халык «Молоко из Орловки» продукциясен бик яратып ашый. Авыл күпмилләтле: биредә руслар, татарлар, чуашлар, украиннар, мордвалар, әрмәннәр, таҗиклар яши һәм эшли. Төрле милләт һәм дин кешеләре биредә бик дус һәм тату. Монда мәчет һәм чиркәүне нибары берничә дистә метр гына аерып тора, ә ике мәхәллә кешеләре бер-берсенә зур хөрмәт белән карыйлар.

Авылда җирле мөселман мәхәлләсе 2015 елның 29 гыйнварында Уралил Закир улы Әхмәдов җитәкчелегендәге инициатив төркем тарафыннан теркәлгән. Шуннан соң ук мәчет төзү мәсьәләләре белән шөгыльләнә башлаганнар. Моңа кадәр җирле мөселманнар күп еллар дәвамында Нәбиулла Мотыйгулла улы Нигъмәтуллин йортында җомга намазларына җыелганнар. Мәчет өчен акча җыя башлаганнар, ләкин кирәкле сумманы күтәп тормыйча, шундук төзелешкә керешкәннәр – бура сатып алганнар, кирпеч кайтарганнар. Бүлекчә идарәсе җитәкчесе Равил Латыйпов һәм «Дружба» нәсел заводы директоры Василий

Белов ярдәм иткәч, эш җайланып китә. Гаҗәп, әмма мәчет рекордлы срокларда төзелә: нигез салудан башлап, мәчет ачылуга кадәр нибары бер ай вакыт үтә. Әлбәттә, беренче имам-хатыйбы булып Уралил хәзрәт Әхмәдов эшли. Ул вафат булгач, менә инде сигез ел имам булып Гайсә хәзрәт Кәримов хезмәт итә.

Мәчет юбилеена барганда Самар өлкәсе мөфтие Талип хәзрәт Яруллин 10 ел элек булган хәлләрне сөйләде:

«Авыл аксакаллары төбәк идарәсенә Орловкада мәчет ачуда ярдәм итүебезне сорап мөрәҗәгать иттеләр. Авылда оештыру җыелышы үткәрергә, Кошки районы һәм авыл җитәкчеләрен, җирле халыкны чакырырга карар кылынды. Бу җыелыштан соң бер ай үтеп, шалтыратып, мәчет ачылуга чакыргач, бик гаҗәпләнгән идем мин!»







Мәчетне төзүдә һәм алга таба эшләтүдә Равил Латыйпов гаиләсе зур ярдәм күрсәткән. Юбилейны үткәрүдә дә төп чыгымнарны бу гаилә үз өстенә алган.

Мәчетнең унъеллыгы өлкәбезнең ерак почмагы өчен чын бәйрәмгә әверелде.

Әйләнә-тирәдә төрле төстәге әләмнәр эленгән, сәхнәдән татар җырлары, мөнәҗәтләр яңгырый, күрше Ульян өлкәсеннән һәм Надеждино авылыннан килгән иҗат коллективлары чыгыш ясый, күпсанлы мәртәбәле кунакларның сәламләүләре яңгырый. Авыл халкын мөһим вакыйга белән котларга Кошки районы башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Андрей Сергеев, мөфти Талип хәзрәт Яруллин, Кошки районы депутатлары вәкилләре җыелышының рәисе Владимир Миронов, “Дружба” нәсел заводы генераль директоры Петр Дубянский, Орловка җирлеге башлыгы Олег Худяков килгәннәр. Алар илебез халыкларының рухи байлыгын, бердәмлеген билгеләп үттеләр, юбилей белән котладылар.



– Мәчет – Аллаһы йорты ул, һәм мин мәчетләребезнең беркайчан да буш булмавын, аралашу, белем бирү, танып белү, тормыш мәсьәләләрен хәл итү үзәкләре булуын теләр идем.

Мәчетнең матурлыгы аның тышкы кыяфәтенә карап түгел, ә тулылыгына карап бәяләнә.

Мин барлык мәчетләр дә тулы булсын, өлкәннәр үрнәгендә балалар да Аллаһы юлын күрсеннәр иде, дип телим. Бу очракта киләчәк буыннар да Ватанын ихлас күңелдән яратучы, тәрбияле һәм намуслы кешеләр булып үсәчәкләр, – дип сөйләде Диния нәзарәте рәисе Талип Яруллин.

Чара Корбан ашы һәм милли ризыклар белән тулы өстәлләр янында дәвам итте, җомга намазы белән тәмамланды.

# ДӘҺШӘТЛЕ ЕЛЛАР ХАТИРӘСЕ



***Сугыш еллары бик кыен вакыт булса да, хәтеремдә авырлыклар гына түгел, ә күбесенчә тырышып, илһам-дәрт белән, шатланып укыганым, йортыбыз бакчасында, урманнарда, колхоз кырларында бик теләп эшләгәнем саклана.***

***Азат Надиров,***
*сугыш ветераны, тыл хезмәтчәне.*

Фаҗигаләр, авырлыклар булса да, мәрхәмәтле кояшның җылы нурлары астында, искиткеч матур җир шарыбызда яшәү – олы бәхет. Ә инде бала һәм яшүсмер чаклар - иң күңелле чор.

Иртән радио тыңлыйбыз, аннан соң эшкә чыгып китәбез. Радиодан: "Наши войска после ожесточенных кровопролитных боев вынуждены были оставить город...", "Наши войска полностью окружили гитлеровские войска в районе Сталинграда и приступили к их уничтожению...» һәм башка кайгылы яисә шатлыклы хәбәрләр тапшыралар. "Вставай, страна огромная!" һәм башка патриотик җырлар безгә көч һәм өмет өстәп тордылар. Шулай ук Рәшит Ваһаповның "Эскадрон", Гөлсем Сөләйманованың "Салкын чишмә" җырлары мине нык илһамландыралар иде. Алар миндә татарлыгымны тагын да көчәйттеләр.

Безнең белән әрәмәгә кадәр, балтырган җыярга йөргән күрше Мәдинә апа башкаруындагы искиткеч моңлы татар халык җырлары да миңа тирән тәэсир итәләр иде. Шунысы да исемдә калган. Бервакыт Мәдинә апа белән әрәмәдә йөргән чакта куе үләннәр арасыннан, минем аягым астыннан "фрр, фрр" итеп үрдәк очып китте. Әллә инде ул да Мәдинә апаның моңлы җырына әсир булып, мин килгәнне ишетмәгән.

Шундый җырлар иҗат иткән халык җиңелмәс, юкка чыкмас, Аллаһы теләсә! Шушы мирасыбыз, хәзинәбез яшь буыннарга да тапшырылсын иде!

Әнкәй белән кышка җитәрлек печән, утын, бәрәңге әзерлибез. Урманда, колхоз кырларында эшләп йөргәндә табигатьнең матурлыгы күңелемне күтәрә, шатландыра иде. Имәннәргә карап, аларның нәкъ менә Шишкин картинасындагы кебек булганнарына инана идем.

Әле сугышка кадәр әткәй белән әнкәй урманга алып барганнар иде. Миңа 4 - 5 яшьләр булгандыр. Имәнле куе урмандагы аланда чишмә янындагы балан куакларының матур ап-ак чәчәкләрен күреп, хәйран калган идем. Әле дә вакыт-вакыт шул могҗизалы күренеш күз алдыма килә.

Лалә апам кечкенә сеңелләр белән йорттагы эшләрне башкаралар иде. Ә мин үлән чабарга яраттым. Шундый кызык булып тоела иде бу эш. Аңардан шулкадәр ләззәт ала идем ки, гомер буена печән чабар идем! Шуңа күрәдер дә шагыйрь Алексей Кольцовның "Косарь" шигыре күңелемә бик якын:

"Раззудись, плечо!
Размахнись, рука!
Ты пахни в лицо,
Ветер с полудня!"

Чапкан үләнне, корыган агачларны - утынлыкны башта бәләкәй арбада ташый идем. Аннары балта белән ваклап, өеп куям.

Эх, якындагы Сок елгабызда балык тотасы, су коенасы иде! Мондый мөмкинлек сирәк эләгә иде шул. Эштән бушамыйбыз.

Аннары сыерыбызны җигә башладык. Колхоз кырларыннан ындырга салам ташый идек. Салам эскертләрен бер карт белән күтәрә идек. Өч яшьле агач сәнәк белән картка саламны биреп торам. Бу эш тә миңа бик ошый иде.

Әнкәй башка хатын-кызлар белән сугу машинасында (молотилка), җилгәргечтә (веялка) эшләде. “Все для Победы!” “Хлеб – фронту!” шигарьләре астында тир түктеләр алар.

Шундый хәлләр дә булгалады – эштән кайтучы бер хатынның кесәсендә күпмедер бөртек ашлык табып, аны төрмәгә утыртканнар иде.

Безгә - балаларга да күп эшләргә туры килде шул ул авыр елларда. Башка яшүсмерләр белән бөртекләрне җилләтә, атлы лобогрейка белән үлән чаба идек.



Шулай, беркөнне урманга баргач, утынлыкка дип, кипкән чыбыкларны арбага төягән вакытта җирдә яткан бер калын, череп, кайрысы гына калган каенда выжылдаган тавышлар ишеттем. Елан түгелдер бит?! Мин кайры астына озын чыбык тыгып карадым. Күрәм, аңа нәрсәдер сыланды. Әнкәй: “Бу бал бит”, - ди. Анда кайдандыр аерылган бал кортлары күче урнашкан булган икән. Бәхетебезгә, яныбыздан ике ир үтеп баралар иде. Алар, төтен чыгарып, пычкы белән каенны кистеләр дә бал тулы зурзур кәрәзләр алып чыгардылар. Үзләренә рәхмәтләребезне белдереп, бал белән сыйладык. Ул кәрәзләрнең бер өлешен озак, әткәй сугыштан кайтканчы, сакладык .

Без, мәктәптә укучылар, колхоз кырларында бәрәңге казый идек. Зур складтагы бәрәңгене сортларга аерабыз. Кайсы – ашханәгә, кайсы – чәчүгә.

Кар астында калмасын дип, кырларда көнбагыш башларын кисә идек. Берзаман шунда эшләгән вакытта безгә зур кисәк ипи бирделәр. Сугыш елларында беренче мәртәбә туйганчы ипи ашадым мин шунда!

Карлы бер көнне Мәмерҗә дип аталган таулы-чокырлы җирдән, трактор чанасына төяп, мәктәбебезгә утынлыкка бүрәнә кисәкләрен алып кайткан идек.

Укытучыларыбыз бик яхшы иде безнең. Камышлылар һәм эвакуацияләнгән балалар бергә укыдык, дус булдык.

Сок елгасына язгы ташуны карарга баргач, имгәнеп кайткан бер фронтовикның бик моңлы итеп гармунда уйнаганы хәтеремдә. Хатын-кызларның күңелсез, сагышлы күзләре хәтеремдә...

Менә, ниһаять, зарыгып көткән Бөек Җиңүгә ирештек. Әткәй сугыштан кайтты. Соңрак күкрәкләре орден-медальләр белән тулган, йөзләрендә шатлык балкыган тагын өч туганыбыз кайтты. Ике туган Заһит абыем Каюмов, сугыштан кайтып керүгә тальян гармунын алып, имгәнгән бармаклары белән моңлы көйләр уйнап җибәрде. Ничә еллар көткән бит ул шушы бәхетле мизгелләрне!

Әлбәттә инде, гаиләбезне кайгы-хәсрәт тә урап узмады. Кайбер туганнарыбыз сугышта һәлак булдылар, кайберләре гарип булып калдылар. Мөкаррәмә апамның ире Хәниф абый сугыштан күзсез кайтты. Әмма бирешмәде, әле музыка мәктәбендә баянда уйнарга өйрәнде. Свердловск шәһәре университетында тарих факультетында укыды. Пенсиягә чыкканчы сукырлар китапханәсе директоры булып эшләде.

Куйбышевтагы Авиазаводта ИЛ-2 самолетын төзүче ике туган Әклимә апам болай дип сөйли иде:

“Без, рус, татар, чуаш, мордва кызлары, баракта бертуганнардай яшәдек. Милли җырларыбызны җырлый идек. Алар безне тагын да якынайтты, заводта эшләргә көч бирде”.

Җиңдек! Бу бәхеттән туган хисләр гомер буе күңелемдә саклана.

Сугыш турындагы кинокартиналарны, бигрәк тә документаль фильмнарны, карагач, ул вакытлар тагын бер кат күз алдымнан үтә.

Кызганыч, җир йөзендә сугышлар беркайчан да туктамый шул. Бүгенге көндә дә ир-егетләребез махсус хәрби операциядә илебез мәнфәгатьләрен яклыйлар.

Бөек Ватан сугышы елларындагы кебек, бердәм булсак, бу юлы да сынмабыз-сыгылмабыз, Аллаһы теләсә!

# ЯЛГЫЗ КАБЕР

***XX гасыр башында Россиядә 1905 һәм 1917 еллар революцияләреннән башланган Беренче бөтендөнья сугышы барышында монархия хакимияте җимерелә, хуҗалыклар таркала, халык бөлгенлеккә төшә. Россия җәмгыяте тирән социаль, милли һәм сәяси кризис кичерә, Үзәк державалар һәм Антанта, «кызыллар» һәм «аклар» арасында каты сугышлар бара...***

***Фәрид Шириязданов***

Шул дәһшәтле еллар истәлеге булып Чулпан һәм Сидяково авыллары арасындагы тау башында ялгыз кабер тора. СССР вакытында аның янында пионерга һәм комсомолга кабул итүләр һәм башка тантаналы чаралар үткәрү гадәте бар иде. Кем җирләнгән соң бу тау башында?



...Антанта илләре Россияне большевиклардан азат итү исәбе белән яшь Совет иленә сугыш ачканнар, дип аңлаталар иде. Ләкин дә моның сере күпкә катлаулырак. Мәсәлән, интервентларның төп максаты - авыр хәлдә калган илне бүлгәләп, һәркайсы үзенә өлеш чыгарырга теләгән, дигән фикер бар.

Чехлар Самарны басып алгач, эсерлар Комуч (Комитет членов Учредительного собрания) төзиләр. Шулай итеп, Самар 4 ай буе Россия башкаласы булып санала. Бу вакытта ил күләмендә канкойгыч сугышлар бара.

Менә шундый катлаулы һәм хәлиткеч чорда, Идел буе Колчак гаскәрләре һәм чехлар кулында булган вакытта, Петроградтан РСДРП (б) мандаты белән Самарга данлыклы революционер Сергей Лазоның якын дусты һәм көрәштәше - Батыргали Ваһапов килеп төшә. Революционерлар буларак, алар патша заманында бергә каторга газаплары кичергәннәр. Ваһаповка «аклар» тылында партизан отрядлары оештыру бурычы йөкләнә.

Ә Сергей Лазоны Ерак Көнчыгышка япон басып алучылары тылында партизан отрядлары оештырырга җибәрәләр. Бу ике легендар шәхеснең язмышлары охшаш. Аларның икесен дә интервентлар ерткычларча җәзалап үтерәләр. Сергей Лазоны японнар паровоз мичендә яндыралар, ә Батыргалине «аклар» җәзалап үтерәләр, җәсаден җирләүне тыеп, гәүдәсен кыргый җәнлекләргә ташлыйлар.

...Батыргали Ваһапов Богырыслан өязе, Иске Ярмәк авылында туып-үсә. Ул үз чорына күрә алдынгы фикерле, укымышлы кешеләр исәбендә санала, авыл мәдрәсәсендә укыганда ахун Хәснулла хәзрәт Баһаутдиновның иң алдынгы укучыларының берсе була, Богырыслан гимназиясен тәмамлый. Беренче Бөтендөнья сугышында унтер-офицер званиесендә сугыша һәм ахырда революция хәрәкәтенә кушыла, РСДРП(б) әгъзасы була.

Богырыслан өязе, шул исәптән хәзерге Камышлы районы җирләре дә, элгәреднән татар-башкорт халкының азатлык яулау үзәге булган. Монда даими рәвештә канлы сугышлар, баш күтәрүләр булып торган, революциядән соң Совет власте урнаштыру чорында да биредә көрәш барган. Идел буе җирләрен Колчак гаскәрләре һәм ак чехлар басып алгач һәм яшь Совет республикасына куркыныч янаганда, бу җирләрдә аеруча дәһшәтле сугышлар бара.

1919 елның мартында Иске Ярмәк авылына Колчак гаскәрләре басып керә, коммунистлар һәм укытучылар Шуран тавындагы умарталыкка качалар. «Аклар» качып өлгермәгән сельсовет рәисе Хәбибулла Гатауллинны тотып алалар һәм авыл уртасындагы мәйданда атып үтерәләр. Калган активистларны чыбыркы белән суктыралар. Ачлыктан интеккән халыкның актык малларын талап һәм атларын алып, китеп баралар.

Бу вакытта «аклар» штабы - Иске Ярмәк авылыннан ун чакрым ераклыктагы Седяково авылында, ә «кызыллар» штабы Мансур авылы янында урнашкан була. Комиссар Батыргали Ваһапов төнлә гаиләсен күрергә Иске Ярмәккә кайта. Моны ишеткән авыл байлары «аклар» штабына хәбәр бирәләр һәм таң алдында Колчак гаскәрләре Батыргалине кулга алалар. Атлы казаклар аны яланөс һәм яланаяк килеш кар өстеннән Седяково авылында урнашкан штабларына куып китәләр. Җәзалап сорау алганнан соң, аны авыл читендәге тау башына алып баралар. Атлы казак аның башын чабып өзә. Башы тау астына тәгәрәп төшә. Коточкыч ачлык елларында бүреләр күп үрчегәнлектән, Батыргалине җирләүне катгый тыеп, ерткычларга калдыралар.

Батыргалинең бертуган абзыйсы Ширияздан Ваһапов, аның улы Шаймәрдән Шириязданов һәм аларның туганнары, караңгы төндә читтәрәк туң җирне казып, аны җирлиләр...

Озакламый белочехларны илдән куалар һәм акгвардиячеләр тар-мар ителә. Шунда Батыргалинең гәүдәсен авыл зиратына күчереп җирләү мәсьәләсен кузгата-



лар. Ни кызганыч, сәясәт киеренке һәм дәһшәтле булу сәбәпле, бу максат гамәлгә ашмый кала.

Тормыш барышында күп нәрсә үзгәрә, шул исәптән кешеләрнең дөньяга карашы да. Күп гыйбрәтле хәлләр онытыла, сансызлана. Тик тарихны сакламаган, битараф булган очракта аяныч хәлләр, кабатланып, тагын да зуррак бәлаләр китереп чыгарырга мөмкин бит.

Менә бу тау башындагы ялгыз кабер дә төрле уйлар тудыра. Анда халкыбызның киләчәген кайгыртып, интервентларга каршы көрәштә үз гомерен корбан иткән легендар шәхесебез җирләнгән. Ни кызганыч, бүгенгәчә Батыргали һәм аның көрәштәшләре кебек ялкынлы йөрәкле батырларга карата төрле карашлар яши. Берәүләр аны хөрмәт итеп, каберен карап, истәлеген саклыйлар, битараф булганнары да бар. Бәлки, шуңадыр да шаукымлы вакыйгаларның кабатлануын күрәбез.

Мәсәлән, чиксез авырлыклар белән җайга салынган СССР тармар ителде. Моннан 107 ел элек 14 дәүләт, Россияне талап, үзара бүлгәләү өчен сугыш ачкан булсалар, бүген инде андый илләр саны 50дән дә узды.

Тарих - ул зирәк укытучы да, тәрбияче дә, ялгышлардан саклаучы һәм киләчәккә юл күрсәтүче маяк та. Тик аны таный һәм зурлый белергә генә кирәк. Шулай булмаса, тарих кырыс хөкемдар һәм каты җәза бирүче булырга да мөмкин.

Төбәгебез тарихын барлаганда аның никадәр тирән һәм бай булуын күрәсең. Мәсәлән, элеккеге Оренбург губернасының Богырыслан өязенә кергән Камышлы якларында һәр тау, урман, чокыр, күл исемнәрендә тарих серләре саклана. Биредә әледән-әле татар-башкорт халкының азатлык өчен баш күтәрүләре булып торган, Пугачёв генераллары Гаврил Давыдов һәм Йосыф Ангалышев монда гаскәр туплаганнар. Бу һәм башка кыйммәтле тарихи сәхифәләр ныгытып өйрәнүне көтеп яталар.

Камышлы төбәгенең мәгърифәт үзәге булуы да билгеле. Илдә наданлык хөкем сөргән чорда белемле муллалар, укытучылар, галимнәр, партия һәм совет хезмәткәрләре чыккан. Иске Ярмәк авылында яңа методлы мәдрәсә ачкан җәдитче-новатор - ахун Хөснулла хәзрәт Баһаутдиновның эшчәнлеге генә ни тора!

Батыргали Ваһапов та - наданлыкка, гаделсезлеккә һәм баскынчы интервентларга каршы барган канлы көрәш чорының күренекле бер вәкиле. Аның турында Халикъ Садри “Безнең таңнар” исемле әсәрендә кыскача язып уза. Анда Батыргали Ваһаповның төрмәдән кайткан чагы сурәтләнә.

“Кеше китә, эше кала”, диләр. Ни кызганыч, тик Батыргали кебек Гражданнар сугышы каһарманнары турындагы истәлекләрнең күбесе хәзер югалган, һәм бу югалтулар дәвам итә. Мәсәлән, Батыргали туплаган партизан отрядлары командарм Михаил Фрунзе җитәкләгән Кызыл армия сафларына кушыла. Аның сафларында Камышлы төбәгендә яшәүче кешеләр дә катнашалар. Ни кызганыч, бу кыйммәтле мәгълүматларның күбесе хәзер инде онытылган.

Батыргалинең көрәштәше - Халикъ Садри Карабаш фронтында военком булып хезмәт итә, аннан соң Самар губкомы секретаре, язучы, Татарстан Язучылар берлегенең литфонды рәисе булып эшли.

Шаһит Җәләев - Гражданнар сугышы герое, бер аягын югалта. Революциядән соң барлыкка килгән иң беренче татар галимнәре исемлегендә була. Икътисад фәннәре кандидаты. Озак еллар Казанның югары уку йортларында белем бирә.

Белемле кеше буларак, ул туганнарыбызны да, тирә-як күршеләрне дә дингә җәлеп итеп яшәде, күпләрне намазга бастырды.



Безгә дә кечкенәдән ислам таләпләрен сеңдереп үстерде. Без, бертуганнар, гаиләләребез белән бергә нәкъ менә әниебез аркасында дин юлыннан атлыйбыз, гыйбадәтләр кылып гомер итәбез. Кызганыч ки, олы абыем белән энем якты дөньядан бик иртә китеп бардылар шул, – дип исенә төшерә иң газиз кешеләрен Мөдәррис абый.

***– Әти-әниегезнең нинди сыйфатларын сагынып искә аласыз, алар сезгә нинди үрнәк күрсәтеп калдырдылар?***

– Икесенең дә сагынырлык, үрнәк алырлык сыйфатлары күп. Әти бик тә тырыш, эшчән кеше иде. Әлхәмдүлилләһ, җитешлектә үстек, бернәрсәгә дә кытлык кичермәдек без.

Йомшак күңелле әтиебезнең бер сыйфаты исә аеруча сокланырлык. Ул башкаларга карата шулкадәр ярдәмчел, кеше хәленә керүчән иде, исләрең китәр! Кемнең нинди проблемасы, үтенече бар, чын күңеленнән аны хәл итәргә, ярдәм кулын сузарга тырышты.

Кайберәүләр, дөнья малына кызыгып, кеше башын таптап узарга да, хәтта туганлык җепләрен өзәргә дә мөмкиннәр. Безнең әти-әнидә бу нәрсә булмады. Нәселебез туган җанлы, бик тату безнең. Бер-беребезне ташламыйбыз, хәл белешеп, ярдәмләшеп яшибез, Аллаһыга шөкер.

Үзләре бик юмарт кешеләр буларак, әти-әниебез бездә дә шушы сыйфатны тәрбияләп үстерделәр. Алар безгә: “Акча эшләдегез икән, җәлләмәгез, малларыгыздан зәкәт чыгарыгыз, сәдакалар өләшегез”, – дип гел әйтеп килделәр. Һәм яши торган саен бу сүзләрнең хак булуын аңлый барасың.

Динебездә безгә зәкәт фарыз ителгән, ягъни мөэминнәр өчен билгеле бер бурыч буларак йөкләнелгән бит. Шуңа күрә аны түләгәч, өстеңнән бер йөк төшкәндәй, күңел җиңеләеп китә, җанга рәхәтлек иңә. Раббыбыз киләчәктә дә ислам таләпләрен төгәл үтәп яшәргә насыйп итсен.

Балачактан эшкә батыр булып, тормыш көтәргә өйрәнеп үстек. Бу да – әти-әниебезнең тәрбиясе.

Хуҗалык эшләрендә аларга һәрвакыт ярдәм иттек. Һәм мин моңа бик шатмын, чөнки хезмәттә чыныгып, эшне сөяргә өйрәнеп үскән балалар тормышта югалмыйлар, үз юлларын табалар, уңышларга ирешәләр. “Оясында ни күрсә – очканында шул булыр”, – ди бит татар халкы.

Гомумән, әти-әни безне үз үрнәкләрендә тәрбияләделәр, бездәге күркәм сыйфатларның, гамәлләрнең барысы да алардан күчкән. Һәм без, үзләренә бик рәхмәтле булып, рухларына догалар кылып яшибез.

Әти-әнисенең үгет-нәсыйхәтләрен күңеленә сеңдереп үскән һәм аларны гомере буе үтәп яшәүче Мөдәррис әфәнде Латыйпов актив рәвештә хәйриячелек белән шөгыльләнә. Мәчетләргә, мәдрәсәләргә, төрле милли чараларга хәләл малыннан өлеш чыгара ул.

"Мөдәррис – бигрәк тә ярдәмчел кеше инде. Авылда төрле бәйрәмнәр үткәргәндә дә, башкасына да еш кына аңа мөрәҗәгать итәбез. Һәм ул беркайчан да кире борып җибәрмәс, һәрвакыт ачык йөз күрсәтеп, хәленнән килгәнчә булышыр. Авылыбыз мәчетләренә дә, бигрәк тә мәдрәсәбезгә аның ярдәме тия.

Пәйгамбәребез с.г.в.нең: "Нәсел-нәсәбегезне белегез, кан кардәшләрегез белән йөрешегез", – дигән нәсыйхәтен үтәп яшиләр алар. Туганнары белән шулхәтле дуслар. Авыл халкы да: "Нәселләре бигрәк туган җанлы инде", – дип соклана үзләренә.

Авылыбызны үстереп, аның данын таратуга үз өлешен кертеп яшәүче Мөдәррис әфәндегә без бик рәхмәтлебез. Аның кебек ир-атлар – алтын бөртеге", – дип фикере белән уртаклашты язмам героеның авылдашы, Гали авылының "Ак калфак" татар хатын-кызлары оешмасы рәисе Кәүсәрия Шәйхетдинова.

Сату өлкәсендә эшләгән әтиләре үрнәгендә Мөдәррис абый да, аның бертуганнары да шушы тармакны сайлап алганнар.

Ул үзе Балашов шәһәрендә мамык-мех техникумын тәмамлаган һәм Оренбург өлкәсенең Әсәкәй авылында склад мөдире булып эшләгән.

Ә инде соңрак, Похвистнево шәһәренә күчеп, анда район кулланучылар җәмгыятенә урнашкан һәм яшь милләттәшебезне бирәдә яңа гына төзелгән колбаса ясау цехының мөдире итеп билгеләгәннәр.

– Әле Әсәкәйдә яшәгән чакларда бервакыт хатыным белән Похвистневога туганнарыбызга кунакка барабыз. Һәм монда төзелеп килгән цехны күреп: "Рузалия, менә безнең өчен салалар", – дип шаярган идем. Фәрештәләрнең "амин" дигән вакытына туры килгән, күрәсең. Чыннан да, ачылган көненнән бирле шушы цехта эшләргә насыйп булды. Бу хезмәтем буенча махсус курсларда белем дә алдым.

Аннан бит инде авыр 90нчы еллар килеп җитте, кулланучылар җәмгыятьләре дә ябыла башлады. Һәм без хатынымның бертуган абыйсы Равил Мостафин белән райпо җирләрен сатып алдык та үзебезнең хәләл колбаса җитештерү цехын ачып җибәрдек. Шулай, 1998 елда "Дуслык" дип аталган предприятиебез барлыкка килде һәм бүгенге көнгә кадәр ике гаилә бирәдә хезмәт итәбез.

Шунысы куанычлы ки, без кредитка кермәдек, барысын да үз көчебез белән булдырдык, булган малларыбызны җыеп, аларны җитештерү эшенә керттек, автоматлаштырылган чит ил җиһазларын сатып алдык. Кирәкле бөтен нәрсәләребез дә бар.

Шушы хезмәтебезне башлап җибәргәч, Аллаһыга шөкер, туганнарыбыз белән бергәләп беренче мәртәбә хаҗ кылырга да насыйп булды, – дип исенә төшерә Мөдәррис Латыйпов.

***– Ә бит туганнар белән бергә эшләве авыр, дигәннәрен ишеткәнем бар.***

– Менә без ике гаилә хәзер ничәмә еллар бергә хезмәт куябыз инде. Рәхәтләнеп эшлибез, бер-беребезгә кырын караш ташлаганыбыз, яман сүз әйткәнебез, акча бүлешкәнебез, бәхәскә кергәнебез юк.

Бервакыт миннән бер урыс кешесе: "Инде күп еллар бергәләп эшмәкәрлек белән шөгыльләнәсез, һәм сездә үзара бернинди дә ызгыш-талаш юк. Ничек шулай килеп чыга соң ул?!" – дип исләре китеп сораган иде. Ә мин аңа шунда ук дөресен ярып салдым: "Без – ислам таләпләрен үтәп яшәүче мөселманнар. Ә безнең диндә туганнар белән талашу – зур гөнаһ ул. Пәйгамбәребез с.г.в. дә: "Туганлык җепләрен өзгән кеше җәннәткә кермәс", – дигән".

Туган җанлылыкның, ярдәмләшеп яшәүнең әҗер-саваплары күп аның. Якыннарын туган итмәгән кешенең тормышының бәрәкәте, рәхәте кими. Дөнья малы – кешене талаштыра, сугыштыра торган нәрсә. Безнең максат акча артыннан куу түгел, ә гаиләләребезне, балаларыбызны тәэмин итеп, башкаларга ярдәм күрсәтеп, хәйрия эшләрендә катнашып яшәү.

***– Җитәкче булуы авырмы?***

– Җиңел, дип әйтеп булмый. Хезмәткәрләребез алдында да, безнең продукцияне сатып алучылар алдында да, эшебезнең сыйфаты өчен дә зур җаваплылык тотабыз.

Без бит хәләл продукция җитештерәбез, шуңа күрә, әлбәттә, барысы да дөрес итеп, тиешле таләпләргә туры китерелеп ясалырга тиеш. Бу яктан инде без бөтенесен дә яхшылап тикшереп, җитди контроль алып барабыз. Безнең ризыкларны сатып алучылар хезмәтебезнең нәтиҗәләре белән канәгать калсыннар өчен зур тырышлык куябыз.

Шулай ук һәр эшчебез өчен уйларга, кайгыртырга, шәхси проблемаларында да хәлдән килгәнчә ярдәм итәргә кирәк.

***– Сез таләпчән җитәкчеме?***

– Йомшаклык та кирәк, таләпчәнлек күрсәтмичә дә булмый. Әмма син хезмәткәрләрең белән дөрес мөнәсәбәтләр булдырырга тиеш. Өсләренә акырырга түгел, тыныч тавыш белән аңлатырга, җиткерергә кирәк. Алар синнән курыкмасыннар, ә хөрмәт белән карасыннар. Үзеңне ничек күрсәтәсең, кул астыңдагы кешеләр сиңа шушындый ук мөгамәләдә булачак.

Шундый мохит тудыру мөһим ки, үзеңә дә, хезмәткәрләреңә дә хезмәт куярга җиңел, эшкә теләп, шатланып килергә булсын.

Аннан соң, җитештергән малларыбыз гына хәләл булырга тиеш түгел бит. Биш вакыт намазыңны укып, сәҗдәдән башыңны

күтәрәсең дә эшчеләреңә акырып-бакырып йөрисең икән, бу инде дини кешегә бер дә килешми торган хәл. Аллаһым сакласын, аларга тавышлансаң, үпкәләтсәң, рәнҗетсәң, без үзләрен кыерсыткан булып чыгабыз. Бу очракта укыган намазларың да, кылган гамәлләрең дә дөрес түгел, һәм алар Раббыбыз тарафыннан кабул ителмәячәк, димәк.

Бер-берең белән аңлашып эшләгәндә Аллаһы Тәгалә юлын да күрсәтә, барысын да җайлый, җиңеллек тә бирә.

***– Эшкуарлык белән шөгыльләнеп китәр өчен нинди сыйфатлар таләп ителә?***

– Иң беренче чиратта, намуслы булу кирәк. Һәм бу – эшне башлап җибәргәндә генә түгел, ә даими рәвештә булырга тиешле сыйфат. Беркайчан да беркемне дә алдарга ярамый, ышанычлы мөнәсәбәтләр булдыру мөһим. Сүз бирдең, вәгъдә иттең икән, син аны башкарырга тиешсең.

Кешене үпкәләтмәскә. “Таш белән атсалар – аш белән ат”, – ди бит татар халык мәкале. Мин башкаларны рәнҗетүдән куркам. Шуңа күрә үзеңә карата күрсәтелгән начар мөнәсәбәткә дә яхшылык белән җавап бирергә кирәк, дип саныйм.

Без шуларның барысын да үтәп эш итәбез, шуңа күрә тауар белән тәэмин итүчеләр дә (поставщики), сатып алучылар да безнең белән курыкмыйча, ышанып эшлиләр.

Эшкуарлык белән шөгыльләнеп китәр өчен кирәкле сыйфатлардан тагын тырышлыкны, эш сөючәнлекне, үҗәтлекне атар идем.

***– Мөдәррис әфәнде, гаиләгез белән дә таныштырып үтсәгез иде. Хатыныгыз белән ничә ел бергә гомер итәсез? Аның нинди сыйфатларына сокланып яшисез?***

– Хәләл җефетем Рузалия белән 40 ел бергә без. Ул дини нәселдән. Бабасы Гали авылы мәчетендә имам булып хезмәт иткән. Әнисе, яшьли тол калып, өч баласын берүзе үстергән һәм, әйтергә кирәк, үзләренә лаеклы тәрбия биргән.

Рузалия – бик тыйнак хатын. Үзен алтынга күмсәң дә, масаймас ул. Кешеләргә карата миһербанлы. Мин һәрвакыт диярлек эштә булгач, балаларыбызны да күбрәк хәләл җефетем тәрбияләде. Кечкенәдән үзләренә динебез таләпләрен өйрәтте. Хатынымнан бик уңдым, шатланып туя алмыйм. Үзенә барысы өчен дә рәхмәтлемен.

***– Егет чактагы мәхәббәт бүгенге мәхәббәттән аерыламы?***

– Яшь вакытта хыялыйлык, романтика кебек сыйфатлар хөкем сөрә бит әле. Ә инде еллар уза торган саен җитдиләнә барасың, тормышка башкача карый башлыйсың. Хатының иң якын кешеңә әйләнә, аңа карата хөрмәт тагын да арта, балаларыңның әнисе булараk, үзенә рәхмәт хисләрең көчәя. Бер-береңнән башка яши алмаганны аңлыйсың. Хатыным – миңа һәрьяклап терәк. Киңәшеп яшибез, бергә эшлибез, бергә гамәлләр кылабыз. Ул булмаса, бер канатың юк, дигән сүз. Олыгая барган саен мәхәббәт тагын да тәмләнә, дип әйтәсем килә.

***– Балаларыгызда нинди сыйфатлар тәрбияләргә тырыштыгыз?***

– Кечкенәдән динебез таләпләрен сеңдереп үстердек. Аллаһыга шөкер, кызыбыз Гүзәлия дә, улыбыз Рәис тә әле мәктәптә укыганда намазга бастылар һәм хәзер дә дин юлыннан баралар. Киявебез Равил, киленебез Динә дә гыйбадәт кылучылар исемлегендә.

Тәкәбберләнмәгез, кешедән көлмәгез, беркемне дә үпкәләтмәгез, тыйнак, ярдәмчел, киң күңелле булыгыз, дип әйтеп килдек. Эш сөяргә өйрәттек. Динебез кушканча, һөнәрле иттек. “Әгәр син балаңа һөнәр бирмәсәң, шушы баланың баласы теләнче булырга мөмкин”, – дигән тирән мәгънәле мәкаль бар. Эшлиләр, үз көннәрен үзләре күрәләр. Әлхәмдүлилләһ, тәртипле булып үстеләр, битебезгә кызыллык китермәделәр алар.

***– Хаҗ да кылгансыз. Изге җирләрдә нинди хисләр кичердегез, нинди теләкләр теләдегез?***

– Аннан җиңеләеп кайтасың. Йөрәк тулы шатлык, бәхет. Тагын барасы килә.

Иң беренче, Аллаһыдан гөнаһларыбызны ярлыкавын сорадым. Гаиләмә, балаларыма, туганнарыма, якын кешеләремә, гомумән, мөселманнарга исәнлек, бәхет, бәла-казалардан саклавын, җәннәтләргә керергә насыйп итүен, илләребезгә тынычлык сорадым.

***– Сезнеңчә, бүгенге көндә татарлар дингә тартыламы?***

– Зур шәһәрләрдәге мәчетләрдә Азия халыклары күбрәк инде ул. Ә менә кечкенә шәһәрләрдә, авылларда күп татарларны күрергә була. Шунысы игътибарга лаек – хәзер яшьләребез дингә тартыла.

Кайберәүләрдән: “Пенсиягә чыккач, намаз укый башлыйм”, – дигән сүзләрне ишетергә була. Ә пенсиягә кадәр яши аласыңмы соң әле?!

Бүген җомгаларда яшьләрне күрәсең дә, күңел җылынып китә. Бу инде – бик тә шатлыклы күренеш.

***– “Бәхет” төшенчәсен ничек аңлатыр идегез?***

– Бәхет – ул Аллаһы Тәгалә биргәнгә канәгать булып яшәү. Әллә нинди байлыкларга, вазыйфаларга кызыгырга түгел, ни барына шөкерана кылып гомер итәргә кирәк.

Эшебез бар, хатыным, балаларым, туганнарым исән-саулар. Дүрт оныгыбызга куанып бетә алмыйбыз. Үз аякларыбызда мәчетләргә гамәл кылырга йөрибез. Иртән уянып, күзне ачкач та, шуларның барысы өчен дә Раббыбызга рәхмәтләр укыйм мин.

Артыбыздан дога кылучы, иманлы балалар калдырабыз. Шуңардан да зур шатлык бармы соң?!

Мин – бик бәхетле кеше, Аллаһы Тәгаләгә мең рәхмәт.

***– Бәхетегез кимемәсен, Мөдәррис абый. Игелекле гомер юлыгызда Раббыбыз сезне Үз ярдәменнән ташламасын.***



*Язмам герое – 47 яшьлек Раил Нурулла улы Гарифуллин белән әңгәмә корганнан соң, аның исеменең мәгънәсе нинди икән, дип кызыксынып, сүзлекне ачып карадым. Сөбханаллаһ, исеме җисеменә туры килә булып чыкты бит! Раил "нигез салучы", "төпле кеше" мәгънәләрен йөртә.*

*Миләүшә Газимова*

# ИМАНЛЫ ҺӘМ ТӨПЛЕ ИР-АТ УЛ!

Раил әфәнде Чаллы Баш авылында туып-үскән.

Мәктәптән соң Кинель-Черкассыда механик-технологик техникумына укырга кергән. Ә икенче курстан аны армия сафларына алганнар.

"Хезмәтемне тутырып кайткач, булачак хатыным белән таныштым. Бераз очрашып йөргәч, өйләнештек.

Гаилә мәшәкатьләре башланды, тормыш күтәргә, акча табарга кирәк иде, шуңа күрә укуымны тәмамлый алмыйча калдым, эшкә урнаштым.

Башта сату белән шөгыльләндем. Заманча әйтсәк, менеджер идем. Соңрак өч ел бер реклама компаниясендә хезмәт иттем.

Реклама эше кызыклы, миңа бик ошады. Шуңа күрә уйланып-уйланып йөрдем дә, тәвәккәлләп, шушы юнәлештә үз фирмамны ачарга булдым. Һәм инде менә бишенче ел уңышлы гына эшләп киләбез, Аллаһыга шөкер.

Күбрәк тышкы реклама һәм интерьер рекламасы белән шөгыльләнәбез.

Кибетләр, матурлык салоннары, сәүдә йортлары өчен алтакталар (вывеска) ясыйбыз.

Вак-төяк эшләрдән визиткалар, календарьлар һәм башка шундый кирәк-яракларны җитештерәбез.

Реклама алтакталары буенча без тулысынча бөтен эшне башыннан алып ахырына кадәр башкарабыз. Ягъни башта үлчәм алабыз, аннан дизайн ясыйбыз, алтакталарны җитештерәбез һәм аларны тиешле җиргә урнаштырып та куябыз. Шуңа күрә шәхси предприятиемне "От А до Я" дип атадым да.

Без шулай ук мөселман календарьларын да ясыйбыз.

Тарихи мәчетнең 130 еллык юбилеена дивар һәм кайтарып ачмалы (перекидной) календарьлар, баннерлар, бүләк пакетлары әзерләдек.

Җәмигъ мәчетендә сатыла торган календарьлар да – безнең эш", – дип сөйли Раил Гарифуллин.

Милләттәшебезнең кул астында фрезерчы (фрезеровщик), хәреф җыючы, бастыручы (печатник), дизайнчы, монтаж осталары эшли.

Ул хезмәткәрләренә йөкләмәләр биреп кенә утырмый, үзе дә рәхәтләнеп кайбер эшләрдә катнаша – үлчәмнәр алырга да барып кайта, монтаж ясарга да чыгып китә.



**– *Җитәкче хезмәте җиңеллләрдән түгелдер?*** – дип кызыксындым әңгәмәдәшемнән.

– Әйе, эшчеләр алдында да, заказ бирүчеләр алдында да, хезмәтнең сыйфаты өчен дә җитәкче өстендә зур җаваплылык ята.

Шулай ук хезмәткәрләремә шәхси проблемаларында да ярдәм кулын сузарга тырышам, чөнки аларны эшче итеп кенә кабул итмим мин, ә, иң беренче чиратта, үзләренә кеше буларак карыйм. Бер гаиләдәй бит инде без. Шуңа күрә алар белән дөрес, ышанычлы мөнәсәбәтләр булдыру кирәк. Бер-берең белән аңлашып, кешелеклелек күрсәтеп эшләгәндә Аллаһы Тәгалә Үз ярдәмен бирә.

**– *Эшегезнең төп принциплары нинди?***

– Әлбәттә инде, югары сыйфатлы хезмәт күрсәтү. Шулай ук безнең өчен клиентларны кайгырту бик мөһим урын алып тора.

Әйтик, заказ бирүченең кыйммәтле алтакта ясатырга акчасы җитми, ди.

Без, аның матди мөмкинлекләренә туры китереп, арзанрак материаллар кулланабыз.

Әмма, моңа карамастан, җитештерү сыйфаты бер генә дә кимеми.

***– Хәйрия эшләрендә катнашасызмы?***

– Әйе, хәлемнән килгәнчә хәләл малымнан өлеш чыгарырга тырышам. Мәчетләргә дә ярдәм кулын сузганым бар.

Аллаһы Тәгалә: «…Җәннәт сакчысы, оҗмах ишеген ач. Әүвәл юмартлар җәннәткә керсеннәр…”, – дигән бит.

Күбрәк биргән саен Раббыбыз сиңа арттырып кайтара. Юмарт булып, бер-беребезгә ярдәм итеп яшәсәк иде.

***– Үз эшеңне ачу җиңел түгел бит. Моның өчен нинди сыйфатлар булуы мөһим?***




– Иң беренче чиратта, көчле теләк булырга тиеш.

Курыкмаска, тәвәккәллек итәргә, гаиләң, балаларың яхшы тормышта яшәсеннәр өчен максатыңа ирешкәнче тырышырга, иренмәскә, эш сөяргә кирәк.

***– Әти-әниегезнең нинди үгет-нәсыйхәтләрен истә тотып яшисез?***

– Ата-анама үз гомеремә сокланам мин.

Кызганыч ки, әтием Нурулла якты дөньяда юк инде. Әнием Асия, әлхәмдүлилләһ, исән-сау, 78 яшен тутырды, Чаллы Баш авылында яши. Намазын, уразасын калдырмый.

Әтием Хөсәен авылыннан, ул шофер иде. Әнием Ульян ягыннан, хисапчы булып эшләде. Әти абыем Наил белән мине кечкенә чагыбызда гел үзе белән мәчеткә, туганнарыбыз җирләнгән зиратка алып бара иде.

Ул эчмәде, тартмады, безгә дә бу гадәтләрнең никадәр начар, гөнаһ булуын аңлатып килде. Аның бу нәсыйхәтен үтәп яшибез – тәмәке, аракыдан ерак торабыз.

Әтиебез бик сабыр, мәрхәмәтле иде. Әниебез гаделлекне, дөреслекне ярата, башкаларга карата кайгыртучан, ярдәмчел.

Үзләрендә булган күркәм сыйфатларны бездә дә тәрбияләргә тырыштылар алар.



Милләтенә, диненә карамастан, кешеләрне яратырга, хөрмәт итәргә өйрәттеләр.

Якыннар белән күрешеп, аралашып гомер итәргә кирәклеген төшендерделәр. Әлхәмдүлилләһ, без шулай яшибез дә.

Әтиебез җирләнгән Хөсәен авылы зиратына баргач та, тугантумачаларга кермичә калмыйбыз. Мин анда Гаетләргә дә еш кайтам.

Әти-әниебезгә барысы өчен дә бик рәхмәтлебез.

***– Тормышта кемнәрдән үрнәк аласыз?***

– Иң беренче чиратта, миңа әти-әнием үрнәк булды.

Дингә килгәч, бөтен кешелек өчен иң камил үрнәк – ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, дип әйтә алам. Аллаһы Тәгалә Коръән Китабында, җирдәге һәм ахыйрәттәге тормыш бәхетле булсын өчен, барлык кешеләргә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иярергә куша.

“Тәхкыйк, Аллаһы Рәсүлендә сезгә иярергә тиешле булган күркәм холык вә яхшы сыйфатлар бардыр, Аллаһыдан савапны һәм ахыйрәттә җәннәтне өмет иткән хәлдә, Аллаһыны күп зекер итүче мөэминнәр өчен”, – диелә “Әхзаб” сүрәсендә.

Гомумән, ислам тормышның төрле тармакларында безгә дөрес юл күрсәтә. Хатыныңа нинди мөнәсәбәттә булу, балаларны ничек тәрбияләү, башка кешеләр белән үз-үзеңне ничек тоту кагыйдәләрен һәм башка бик күп нәрсәләрне төшендерә. Динебез – бетмәс-төкәнмәс гыйлем чыганагы ул. Дини китаплар укыган саен яңа белем алам, рухи байлыгымны үстерәм, холкымны тәрбиялим.

***– Ә дингә ничек килдегез?***

– Әйткәнемчә, әти-әниебез күңелебезгә дини орлыклар салып үстерергә тырыштылар.

Утыз яшемдә, Аллаһы Тәгалә тәүфыйк-һидаят биреп, намазга бастым, исламга ныклап кереп киттем.

Шәһәребезнең “Яктылык” мәктәбендә Җәмигъ мәчете имамы Ильяс хәзрәт Гыйрфанов алып барган дини дәресләрдә белем алдым. Сөбханаллаһ, Коръән укырга өйрәндем. Раббыбыз насыйп итсә, хаҗ кылу ниятем бар.

***– Дин юлына баскач, нинди үзгәрешләр барлыкка килде?***

– Күпләрдән: “Гыйбадәт кыла башлагач, Раббым миңа һәр адымымда булыша”, – дигән сүзләрне ишетергә туры килә иде. Бу, чыннан да, шулай икән! Аллаһы Тәгаләнең яклавын-саклавын, ярдәмен тоеп яшим.

Намаз кешене җан, тән, күңел пакьлегенә, тәртипкә өйрәтә, җаваплылык хисен тәрбияли. Намаз укыгач, рәхәтләнеп китәм,

өстеңнән бурычлар төшкән шикелле, җиңеллек килә.

Без бу дөньяда кунаклар гына бит, мәңгелеккә китәсебез бар. Тормышта мал куарга гына түгел, ахыйрәт турында да уйларга, аңа әзерләнергә кирәк – дин кушканча яшәргә, игелекләр кылырга, намаз укырга, күркәм холыклы булырга. Күбрәк рухи байлык җыярга.

Теге дөньяда барысы өчен дә җавап бирәчәкбез. Кеше теләсә кайсы вакытта китеп барырга мөмкин. Ә ул намазга басып өлгергәнме? Изгелекләр кылып өлгергәнме?

Бакыйлыкка буш кул белән китүчеләр арасында булмасак иде. Аллаһы шундыйларның сүзләрен әйтә:

"Үлем фәрештәсе килеп ябышкач, ул кеше әйтер:

"Әй, Раббым, мине кире кайтарсаң иде, нинди изгелекләрне калдырган булсам, бөтенесен дә кылыр идем".

Дин кешене ихласлылыкка өйрәтә. Ниятләребез, гамәлләребез ихлас булырга тиеш. Һәм мәчет эчендә генә түгел, аннан чыккач та ихлас булып калырга кирәк.

Аллаһы йортына күбрәк милләттәшләребез йөрсен иде, намазга бассыннар иде, дигән теләктә мин. Мәрхәмәтле, намуслы, гадел, тәртипле, җаваплы булып, кешеләрне ихтирамлап гомер итсәк, ике дөньяда да бәхетлеләр исемлегенә керербез, инша Аллаһ.

***– Татар-мөселман чараларында катнашасызмы?***

– Бик теләп. Кызым укыган "Яктылык" мәктәбендә, Җәмигъ мәчетендә өмәләр оештыралар. Милләттәшләр, диндәшләр белән бергә уртак эштә катнашуы шундый рәхәт, күңелле!

Мөселман форумнарын да калдырмаска тырышам. Шушындый чараларга күбрәк татарлар килсен иде, дип телим.

***– Раил әфәнде, гаиләгез белән таныштырып үтегез әле.***

– Хәләл җефетем Руфия белән 26 ел бергә гомер итәбез.

Ике кыз тәрбиялибез. Әминәбез университетта, тарихи факультетта белем ала. Ә кечкенәбез Әмирә "Яктылык" мәктәбендә укый, быел өченче сыйныфка күчте.

***– Хатыныгызның нинди сыйфатларына кызыгып өйләндегез?***

– Яшь чакта, беренче чиратта, чибәрлеккә кызыгасың бит инде (елмая). Аллаһыга шөкер, тышкы гүзәллеге дә бар, эчке дөньясы да матур аның. Акыллы, уңган, гаилә учагын саклаучы.

***– Бәхәсләшкәндә кем беренче булып юл бирә?***

– Йомшак күңелле хатын-кызга мин күбрәк юл бирергә тырышам.

***– Арагызда көнләшү хисләре туамы?***

– Яраткач, көнләшкәлисең инде ул. Ә болай, моңа сәбәп биргәнебез юк.

***– Кызларны тәрбияләүнең үзенчәлекләре бармы?***

– Алар нечкә күңелле бит. Үзләрен йомшаклык белән, назлап, мәхәббәттә үстерергә кирәк. Вәгазьләр сөйләп, киңәшләр биреп тәрбиялим.

Ана телен онытмаска, киләчәктә татар егетенә кияүгә чыгарга, ирегезне хөрмәт итәргә, балаларыгызны татар итеп үстерергә кирәк, дип гел сөйләп торабыз.

Әлхәмдүлилләһ, кызларыбыз тыңлыйлар. Аларга кайчак сүз белән дә әйтеп торасы юк, күз карашымнан ук аңлыйлар.

***– Гаилә бәхетле булсын өчен ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр нинди булырга тиеш?***

– Мәхәббәт булуы кирәк. Аны гомер аша үткәреп, саклап калу мөһим. Үткән белән яшәмәскә, бүгенге көндә булганның кадерен белергә.

Бер-береңә юл биреп, гафу итеп, аңлашып, киңәшләшеп, түземлелек күрсәтеп яшәсәң, гаиләдә бәхет хөкем сөрәчәк.

Ачуланышсаң да, озак үпкә тотмаска, шунда ук дуслашырга кирәк.

Кешенең гомере бер мизгелдә өзелергә мөмкин. Менә минем этием төшкә таба хастаханәгә эләкте, ә төштән соң күзләрен мәңгелеккә йомды.

Әйтик, хатын белән ир талаштылар, ди. Берсе өйдән чыгып китте. Ә аның белән берәр куркыныч хәл була калса? Ул инде башкача әйләнеп кайтмаса?

Гафу итешеп өлгермәгәнең гомерлеккә үкенеч булып калачак бит.

Һәрхәлдә, гаиләне саклап калырга тырышырга кирәк.

***– "Ирне ир иткән дә – хатын, чир иткән дә – хатын" дигән мәкаль бар. Хәләл җефетегез сезне ир итеп яшиме?***

– Акыллы халкыбыз әйткән бу сүзләр белән тулысынча килешәм. Хатыннан бик күп нәрсә тора.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм:



«Тормыш – шатлык һәм ләззәт ул, ә тормыштагы иң зур шатлык – изге хатын», – дигән.

Руфия мине хөрмәтләп яши. Кызларыбыз алдында да минем абруйны саклый. Аларга ир кешегә нинди мөнәсәбәттә булырга кирәклеген үз үрнәгендә күрсәтә.

Минем фикерем белән санаша, сүземне тыңлый, һәрвакыт ярдәм кулын суза. Мин аңа бик рәхмәтлемен.

***– Үз холкыгызны бер-ике сүз белән ничек тасвирлар идегез?***

– Максатка омтылышлы, дип әйтер идем. Шулай ук мин – оптимист кеше. Күңел төшенкелегенә

бирелмим. Дин буенча да бу – зур гөнаһ бит. Ә инде күңел төшкән чаклар булса да, аять, хәдисләр укып, догалар кылып, үз-үземне тынычландырам.

***– Кимчелекләрегез өстендә эшлисезме?***

– Кешегә гомере буена үз өстендә эшләргә, кимчелекләрен төзәтергә, холкын яхшы якка үзгәртергә тырышырга кирәк.

Ул тегенди, ул мондый, дип, башкаларны тәнкыйтьләгәнче, син, иң беренче чиратта, үзеңә игътибар итәргә тиеш.

Дингә килгәч, мин моны тагын да яхшырак аңлый башладым.

***– Буш вакытларыгызда нәрсә белән шөгыльләнәсез?***

– Китаплар укыйм. Җәйләрен балык тотам, кышларын чаңгыда, тимераякта шуам. Мунча керергә яратам.

***– Тормышта теләгәнегезгә ирештегезме? Әллә яулап аласы үрләр әле алдамы?***

– Әгәр дә мин бер максатыма ирештем икән, үз алдыма яңа максат куям. Башкача булса, кеше үсештән туктый.

***– Раил әфәнде, Аллаһы Тәгалә сезгә хаҗ кылырга насыйп итсә, изге җирләрдә Аңарданниләр сорар идегез?***

– Раббыбыздан гөнаһларымны гафу итүен үтенер идем.

Өммәтебез, яшьләребез, бер Аллаһы Тәгаләгә ышанып, мөселман һәм татар гореф-гадәтләрен саклап яшәсеннәр һәм аларны киләчәк буыннарга тапшырсыннар иде, дип теләр идем.

Йа, Раббым, тәкъва, хәерле мөселманнардан, Үзең яраткан бәндәләрдән булсак иде, дип сорар идем.

***Чемпионат Восточной Европы федерации WPSO (0+) прошел в Тольятти в 20-х числах июня.***

***ya.ru***

# «У меня была своя цель»:

## самарец Шамиль Гимаев стал абсолютным чемпионом Европы в пауэрспорте




Подготовка к чемпионату прошла в обычном режиме. Гимаев подчеркнул, что поддержка семьи придала ему сил: «Я выполнил свою задачу на 10 из 10». Он установил новый региональный рекорд, победил в личном и абсолютном зачете, став чемпионом Европы.

Теперь его цель – звание заслуженного мастера спорта и титул чемпиона мира. Ранее Гимаев выиграл Кубок мира НАП, установил мировой рекорд и впервые поднял вес больше собственного. Также он получил удостоверение мастера спорта международного класса в строгом подъеме штанги на бицепс.

Мастер спорта международного класса, артист и финалист известного спортивного шоу Шамиль Гимаев рассказал о своих новых достижениях.

Чемпионат Европы в Тольятти стал для него третьими международными соревнованиями подряд. Несмотря на плотный график выступлений, Гимаев планировал сделать перерыв до конца августа, чтобы сосредоточиться на открытии своего зала для любителей армрестлинга и строгого подъема на бицепс.

Спортсмен отметил, что впервые выступал на соревнованиях федерации WPSO и был рад, что они прошли в Самарской области. Незадолго до этого он занял третье место на Кубке мира WRPF в Петербурге, несмотря на спорное судейство.



# ГОМЕР ТАУЛАРЫ БИЕК

*Бүген сүземне ерактан башлыйм әле. Самарда “Бердәмлек” газетасының 35 еллык юбилей тантанасы тәмам булгач, кайту юлына юнәлдек. Шулчак алдан баручы ике ханым сүзләренә игътибар итәргә туры килде.*

***Нурсинә Хәкимова***

Аларның берсе:

– Ии, Раббым! Ерак чакрымнарны үтеп, Нурсинә Хәкимова белән танышыр, аның белән сөйләшер өчен дип килгән идем бит!

Теләгем кабул булмады, бу юлы да сөйләшә алмый кайтып китәргә туры килә инде, – дип уфтанды.

Мин аны-моны әйтергә өлгерә алмый калдым. Миңсылу апам:

– Кызлар, сезне нинди проблема борчый? Нурсинә артыгызда басып тора ич! – дип елмайды.

Менә шулай язмыш мине Исаклы авылында гомер итүче Фәния ханым Сәлахова белән очраштырды. Фойега чыккач, без аның белән аралаштык, телефон номерларыбыз белән алыштык. Ә тиздән язмыш мине Исаклыга алып килде. Һәм мин Фәния апаның тормышы һәм язмышы белән якыннанрак таныштым. Ә ул хәтер йомгагын сүтә торды:



«Мин Камышлы авылында биш балалы гаиләдә туып-үстем. Әтиебез Исламнур – Бөек Ватан сугышы ветераны. Әниебез Ләбибә (соңрак аңа да Бөек Ватан сугышы ветераны дигән исем бирелде) гади колхозчы иде.

Әткәйнең беренче хатынын яшен сугып үтергәч, ул, улы Исмәгыйльне алып, Куйбышевтан (хәзер Самар) Камышлыга барып төпләнә. Әниемне бик ошатып йөри ул. Колхозда тракторчы булып эшләгән унсигез яшьлек кызга: «Ләбибә, әйдә, язмышларыбызны бергә бәйлик! Мин беркайчан да сине рәнҗетмәм, әрмәгән урынга утыртмам, син гомер буе минем сөекле, яраткан хатыным булып яшәрсең», – ди.

Әткәйнең ихлас күңелдән әйтелгән шушы сүзләрен ишеткәч, бигрәк тә кечкенә, ана назыннан мәхрүм калган сабыйны кызганып, әнием үзеннән ун яшькә олырак кешегә тормышка чыга. Алар бер-берсен ихтирам итеп, яратып яшиләр.

Ләкин ни кызганыч! Әтиемә ат типкәч, ул 63 яшендә бакыйлыкка күчте. Ә әнкәй 95 яшенә кадәр яшәде».

Фәния ханым сүзләренә караганда, Исламнур ага белән Ләбибә апа балаларында асыл сыйфатлар тәрбияләгәннәр.

Мәктәпне уңышлы тәмамлагач, Фәния Куйбышев медицина институтында цитолог һәм гистолог белгечлекләрен үзләштерә. Соңгы курста укыганда кияүгә чыга. Бербер артлы кызлары Лилия белән уллары Руслан дөньяга киләләр.

Ә укуын бетергәч, Фәния апаны юллама буенча Татарстанның Әлмәт шәһәренә эшкә җибәрәләр. Бераздан соң ул, гыйлемен тагын да үстереп, табиб-биохимик дип аталган һөнәр иясенә әйләнә.

1980 елда яшь гаилә Исаклы авылына килеп төпләнә. Җирле хастаханәгә эшкә урнашкач, аларга фатир бирелә.

Ул вакытта хастаханәнең башлыгы тәҗрибәле белгеч Анатолий Иванович Орехов була. Фәния ханым, биохимик буларак, лабораторияне җитәкли. Ул әле дә яраткан хезмәтендә үткән гомерен исенә төшереп сөйләргә ярата.

«Мин эшкә керешкәндә, биредә бары тик берничә кеше иде. Тора-бара, кечкенә лабораторияне киңәйтеп җибәргәч, коллективыбызда уннан артык хезмәткәр булды.

Заман таләпләренә җавап бирерлек чит ил аппаратураларын сатып алгач, эшебездә тагын да югары күрсәткечләргә ирешә башладык. Хастаханәбезнең даны ерakларга таралды.

Төрле милләт вәкилләре арасында мөселман кардәшләребез дә бар иде. Фәнүзә Ямалетдинова белән Гүзәл Зәйнуллина – оста табиблар, ә Гөлсинә Биктимирова, Гөлсинә Хисамиева, Мәрьям Хәкимова яхшы лаборантлар булып танылдылар. Алар белән кулга-кул тотынып эшләве бик рәхәт һәм җиңел иде.

Аллаһыга мең шөкер, балачагымнан хыялланган һөнәрне үзләштереп, яраткан хезмәтемә гомеремне багышладым. Шуның өчен әле дә эшемне һәм коллективымны сагынып искә алам һәм аларга чын күңелемнән рәхмәтләремне җиткерәм».

Шунысы гына кызганыч, Фәния ханым карьера баскычы буйлап югарыга таба атлаганда, аның шәхси тормышы таркалып

куя. Аерылышуны авыр кичерә Фәния ханым. Әмма бирешми, түзә. Бигрәк тә кыен чакларда аны әтисенең: «Кызым, тормыш ал да гөл генә булып тормый, күп авырлыклар да очрар. Түземле, нык, сабыр булырга тырыш! Бүген көн болытлы булса, иртәгә кояш чыгар», – дигән сүзләре юата, көч өсти, алга атларга ярдәм итә.

«Дөрес, арабызда яхшы кешеләр күп. Аллаһы Тәгалә сынауларын бирсә, ярдәменнән дә калдырмый, – дип дәвам итә әңгәмәдәшем. – Бирөдә туганнарым булмаса да, Фатыйх ага белән Гөлҗиһан апа Гыйниятуллиннар, Исаклыда мәчет төзүче Гамәл әфәнденең әби-бабасы – Имаметдин белән Соруриҗан Җамалетдиновлар, Айсә һәм Әминә Рахмаевлар, Эльвир ага белән Наилә апа Ибраевлар, Йосыф ага белән Сания апа Мостафиннарга миңа күрсәткән игелекләре өчен бик рәхмәтлемен».

Гомерләр үтә тора. Исаклыда төрле милләт вәкилләре яшәсә дә, бирөдә һәрвакыт үзара дуслык, татулык мөнәсәбәтләре хөкем сөрә. Фәния Исламнур кызы бөтен мәхәббәтен, көчен балаларына һәм авыруларны дәвалауга бирә. Аның тормышы «Яшәвемнең мәгънәсе – кешеләргә хезмәт итү» дигән шигарь астында уза.

Еллар үткән саен күренекле табибның абруе үсә бара. Ул яраткан хезмәтенә 56 ел гомерен багышлап, «Федераль хезмәт ветераны», «Россиянең хөрмәтле доноры» исемнәренә лаек була, 2020 елда губернатор Дмитрий Азаров тарафыннан «Кешеләргә хезмәт иткән өчен» мактау билгесе белән бүләкләнә.

Исаклыда яшәү дәверендә Фәния апа:

«Йа, Раббым! Бирөдә мәчет белән татар зираты булса, мин беркая да китмичә, шушында гына төпләнеп калыр идем», – дип уйлый. Аллаһының рәхмәте, аның теләкләре кабул була бит – авылда бер-бер артлы мәчет белән татар зираты барлыкка килә.

Менә шулай үтә аның гомере. Яшьлек бер генә, кадерен бел генә, диләр бит. Көннәрдән беркөнне, эштән бушаган арада, уйланып йөри торгач, аның күңелендә өрҗаңа өй салып керү дәрте кузгала. Ул, җирле хакимияткә мөрәҗәгать итеп, өй салырга урын сорый. Бирөдә аңа уңай җавап кайтаралар.

Фәния ханым өенә беренче нигез ташын салыр өчен авыл читендәге биек, мәгърур тауларга сыенып утырган биеклекне, ә аскы якта үз алдына нидер көйли-көйли агып ятучы елга буен сайлый.

Бераз алга китеп әйтәм. Аңардан соң монда башка кешеләр дә килеп урнашып, матур өйләр төзи башлыйлар. Ә бистәгә «Җиңү» исеме бирәләр.

Билгеле, өй салу ялгыз хатын-кыз өчен ансат бирелми. Шушы авыр эшендә аңа үҗәтлеге, үзсүзлелеге, тырышлыгы ярдәм итә. Ун ел дигәндә, Фәния ханым балалары белән үзе салган йортның ишеген ачып керү бәхетенә ирешә.

Бүгенге көндә аның йорты аллы-гөлле чәчкәләргә күмелеп утыра. Бакчаның бер читендә зур гына беседка төзеп куйган. Улы Руслан белән бергәләп өр-яңа мунча да өлгерткәннәр.

Аның балалары бик тәртипле булып үсеп җиткәннәр. Югары уку йортларын тәмамлап, үз тормышларын корганнар.

Бүгенге көндә Лилия – Мәскәүдә, ә улы Руслан Самарда үз гаиләләре белән яшиләр. Алар хөрмәткә лаеклы әниләренә дүрт онык бүләк иткәннәр.

Лилия белән ире Русланның кызлары Камилә мәктәпне «Алтын Йолдыз» медаленә тәмамлаган. Фәния ханым өчен бу горурлык булып тора.

Балалары турында сөйләгәндә, ул әнисе Ләбибә белән бертуган сеңелесе Нурияне дә телгә алды:

«Балаларны ялгыз тәрбияләве авыр шул. Кызым белән улымны карашып тәрбияләшкән сеңелем Нуриягә һәм мәңгелеккә күчкән газиз әнкәемә, абыйларыма Аллаһының зур рәхмәтләре яусын».

Фәния апа бүгенге көндә дә оптимистик рухта яши. Ул үзен туганнарыдай күргән танышлары һәм дуслары белән аралашып гомер итә. Алар бергә җыелышып, гамәл кылырга мәчеткә йөриләр, дини мәҗлесләр, дөньяви бәйрәмнәр үткәрәләр.

Татар матбугатын да укып бара Фәния апа. Аеруча «Бердәмлек» газетасын ярата икән.

«Мин бу басманы чыга башлаган көннәреннән үк өемә яздырып алам. Балаларым да әлеге газетаны



укып, татарча укырга, сөйләшергә өйрәнеп үстеләр. Аны чыгаручыларга зур рәхмәт!

Балаларыма газетаны укыгыз, дип әйтеп киләм. Ә улым Руслан: «Әнкәй, әлегә сез укый торыгыз инде. Без көне-төне эш белән чабабыз бит, чөнки тормыш күтәргә кирәк. Балаларны урнаштырып, бераз буш вакыт барлыкка килгәч, һичшиксез, без дә «Бердәмлек»не укырбыз. Чөнки ул иманлы булырга да өнди, дөнья хәлләре белән дә таныштырып тора, рухи яктан да баета. Шуңа күрә газетаның гомере озын булсын иде», – дип әйтте».

Язмамны тәгәлләп, мин дә үз фикеремне җиткерим әле. Адәм баласының гомер тавы биек. Тик шунысы бар – югарыга күтәрелергә дә мөмкинсең, түбәнгә төшеп китүең дә бар. Барысы да кешенең үзеннән тора. Ә язмам герое тормышта очраган авырлыклардан сынмаган-сыгылмаган, гел биеклеккә генә омтылган. Шуның белән ул Кеше исеменә тап төшерми яшәгән, барыбызга да үрнәк булырлык күркәм шәхес булып калган.




# Почему пользователи сети перестают писать на татарском

***Разработчик из Иннополиса Булат Камалов создал татарскую раскладку для русскоязычных пользователей и рассказал редакции «Миллиард.Татар» о том, чем она отличается от обычной, как увеличить присутствие татарского языка в интернете, и почему люди отказываются от татарской клавиатуры и перестают писать на родном языке.***

***milliard.tatar***

## Вместо того, чтобы написать коряввенькое «рэхмэт», люди предпочитают совсем отказаться от татарского

***– Вы решили разработать татарскую клавиатуру, где татарские буквы не включены в основной ряд клавиш. Расскажите, чем это объясняется?***

– Простое исследование в Яндекс.Вордстат показывает, что люди чаще ищут в интернете татарские термины, используя транслитерацию в русский язык («рэхмэт сузе» вместо «рәхмәт сүзе»). Я связываю это с тем, что большое количество татар в качестве основного языка используют русский, а значит, на их устройствах установлена именно русская, а не татарская раскладка клавиатуры. На их устройствах просто нет татарских букв.

В данном случае сама по себе транслитерация не является проблемой – это всё ещё татарский язык. Но проблемой являются случаи, когда вместо того, чтобы написать в мессенджере такое вот коряввенькое «рэхмэт», люди предпочитают совсем отказаться от использования татарского языка и писать сообщение без него. Я не знаю, как можно было бы подсчитать количество таких случаев, но я точно знаю, что они есть, потому что я сам такой.

## Это помогло бы привнести больше татарского языка в интернет

***– А почему вы решили заняться этой проблемой?***

– Началось все с того, что я занимался проектом, который предполагал локализацию на татарский язык. Мне трудно писать на татарском, используя русскую клавиатуру, но если переключиться на татарскую клавиатуру, становится невозможно писать на русском. Поэтому у меня появилась очень простая идея – взять обычную русскую клавиатуру и добавить на нее же татарские буквы. Это оказалось удобно.

Когда я погрузился в вопрос татарских клавиатур, оказалось, что эта мысль пришла в голову не только мне. В интернете мож-




*Фрагмент кодовой базы сайта https://chitaem.online*

но найти несколько проектов, где люди делают ровно то же самое: берут русскую клавиатуру и добавляют туда татарские буквы.

Сейчас главная задача – сделать так, чтобы эта татарская раскладка попала в операционные системы, то есть, чтобы возможность её установить была сразу при настройке устройств и операционки. Такая раскладка дает возможность не переучиваться, но пользоваться и татарскими буквами. Мне кажется, это помогло бы привнести больше татарского языка в интернет.

***– А это вообще выглядит реальным – добиться добавления такого рода клавиатуры в операционные системы?***

– Возможно, для этого нужно просто уговорить разработчиков операционных систем, чему может способствовать большое количество подобных обращений. Пока что я обращался в официальную поддержку Microsoft и Apple, Google и Яндекс, при этом два последних уже создают татарскую раскладку для мобильных устройств. Пока что никакого дельного отклика на мои запросы не было, идут стандартные отписки формата «Спасибо за обращение! Мы рады, что вы нам это предложили!» А Microsoft и Apple и вовсе не ответили.

Для более эффективного воздействия и решения этого вопроса у меня пока что в планах найти людей, которые были бы с этим связаны. Обращаться через людей, которые имеют отношение к этим компаниям и обратиться к ним напрямую – это было бы более эффективно.

С Linux всё оказалось гораздо проще, поскольку это Open source, в котором можно просто прийти в открытую библиотеку, которая занимается разработкой этих клавиатур, и предложить им уже написанный код, а дальше заливается готовая раскладка. То есть при дальнейшей установке пользователями эта раскладка уже будет внутри программы. Сейчас она относится к так называемым экзотическим раскладкам, то есть сразу вы её не увидите, нужно будет покопаться в настройках и включить ей. В этом направлении я тоже планирую работать, чтобы она была видна пользователям сразу.

## Зачем делать татарские буквы дополнительной функцией, а не основными клавишами?

***– А созданием мобильной раскладки вы не занимались?***

– Нет, как раз-таки с мобильной раскладкой есть некоторые трудности – её пока нет вообще нигде. Можно зайти на сайт – *https://800147.github.io/rtu/*, там есть небольшой полигончик, где можно попробовать ту клавиатуру, которую я предлагаю. Пока что был ответ только от Яндекса. Есть еще Microsoft swift клавиатура, к которым я тоже обращался – они пообещали обязательно сделать такую, как я предлагаю. Но после моего обращения они также обновили инструменты, которые позволяют пользователям самим добавлять клавиатуры, до этого он работал с перебоями.

***– Что для этого могут сделать обычные пользователи, которые не будут сами заниматься созданием индивидуальных раскладок?***

– Наверное, большое количество подобных запросов в официальную поддержку – возможно, это тоже поможет.

***– А какими татарскими клавиатурами вы пользовались до этого? На мобильных устройствах, в частности для IOS, не так много хороших вариантов – их практически нет.***

– На самом деле, я не так часто пользуюсь татарской раскладкой вообще. А на мобильном устройстве и вовсе не пользуюсь. Если мне нужно что-то написать по-татарски, я пользуюсь собственным инструментом – захожу на сайт, пишу нужное татарское слово, копирую в буфер обмена и так отправляю. То есть у меня самого татарский язык не то, что не является основным, мне не с кем на нем разговаривать. Поэтому все применение татарского языка мной – это буквально пару словечек «рәхмәт» или «сәлам».

Поэтому, собственно, идея этой клавиатуры исходит именно из такого запроса. Это не «татарская» клавиатура, а в первую очередь «русская» клавиатура, в которой есть возможность писать по-татарски. Там предполагается, что словари для свайп-ввода будут оставаться русскими.

## Русскоязычным пользователям не нужны постоянно клавиши Ә, Ң, Җ, Ү, Ө и Һ

***– А вы пробовали татарские клавиатуры?***

– Да. Я пробовал устанавливать на свой телефон татарскую раскладку, она выглядит очень здорово – в основе русские буквы,




*Выбор раскладки в Fedora Linux*

но при долгом нажатии появляются татарские. Но писать на русском так не удобно, потому что периодически пользователю предлагаются татарские слова, это мешает. Поэтому решение я предлагаю такое. Но мне почему-то казалось, что для людей татароязычных (которые и пишут на татарском) точно есть удобные мобильные клавиатуры.

***– Вы сказали, что это очень разные направления разработки – клавиатура для русскоязычных и татароязычных татар. Почему?***

– Помимо автоисправления слов, есть еще расположение кнопок, потому что в клавиатуре компьютера просто не хватает кнопок, чтобы попытаться их все удобно расположить. Соответственно, классическая татарская раскладка создана для тех, кто пишет на этом языке, то есть буквы расположены на основных клавишах, а не через alt, потому что они нужны постоянно. Для русскоязычных пользователей, которым не нужны постоянно такие буквы как Ә, Ң, Җ, Ү, Ө и Һ, эти буквы нужно выносить в третий слой, чтобы они не мешали, но были в доступе при необходимости.



*Концепт мобильной клавиатуры, доступный по адресу https://800147.github.io/rtu/playground/*

На мобильных устройствах самая главная загвоздка заключается в словарях, автоисправлении и подсказках. Второе направление, которым я занимаюсь – не мешать людям писать по-русски, но давать возможность использовать иногда татарские буквы.

## Преподаватели татарских групп в школе детей ничему толком не учили – «вы же и так знаете татарский»

***– А сами татарский язык вы хорошо знаете?***

– Нет, к сожалению. Я с детства на татарском говорил только с бабушкой и дедушкой, но сейчас такой возможности нет, общения очень мало. Язык в таких условиях забывается, очень жаль, что практиковать его не с кем. Есть, конечно, на работе коллеги, у которых очень хорошее знание татарского языка, но здесь появляется другая проблема – им будет тяжело смотреть, как я долго пытаюсь что-то вспомнить и связать два слова. Было бы хорошо, иметь кого-то своего уровня и вместе с ним говорить. Кажется, у нас даже есть курсы татарского, но на это просто не хватает времени, при желании все есть.

У меня, кстати, на фоне изучения проблем с татарским языком, поменялось мнение об этих «Сәлам», написанных через Э, или каких-то других подобных словечках. Мне уже даже нравятся такие вещи, потому что человек хотя бы с русскими буквами, но пишет татарские слова, обозначает, что ему татарский язык не чужд, что здесь он считает уместным использовать и татарские слова. Гораздо большей проблемой сейчас является то, что люди отказываются от татарских слов. Именно эту проблему пытается решить моя клавиатура.

***– Учитывая то, что вы казанский, в школе вы, наверное, изучали татарский язык?***

– Да, в наше время он еще был обязательным. Но там была немного другая проблема. Поскольку все классы делили на русские и татарские группы, преподаватели татарских групп детей ничему толком не учили – «вы же и так знаете татарский». В основном мы просто читали книжки, у нас не было какого-то серьезного изучения правил татарского языка. Мне кажется, что русские дети, выпустившиеся из школы, знали татарский лучше, чем я. По крайней мере они точно изучали правила и новые слова.

## Интерактивные книги будут не только завлекать ребенка, но и чему-то учить

***– Вы сказали, что к этой идее пришли, работая над другим проектом. Расскажите, чем вы вообще занимаетесь?***

– Мы с женой работали над проектом интерактивных онлайн-книг для детей. То есть дети могут просматривать на планшете какую-то интерактивную онлайн-книгу, которая еще и будет чему-то обучать. То есть там есть книги о проектном мышлении, книга, которая поможет ребенку собирать рюкзак. Страницы можно перелистывать – там есть анимация перелистывания, при этом внутри на страницах книги есть анимация и мини-игры. Таким образом можно завлекать ребенка, чтобы он еще и учился чему-то. В процессе работы мы решили, что это было бы очень интересно и на татарском языке.

Работая уже над татарской частью проекта, мне нужно было где-то менять формулировки или править текст переводчика на татарском языке, так я и обнаружил необходимость в отдельных татарских буквах.

***– Вы сказали, что татарский язык, в принципе, не используете. Откуда вы родом?***

– Я родом из Казани, а сейчас мы с женой живем и работаем в Иннополисе. Общение здесь происходит на русском языке, татарский язык тоже нет-нет да и проскальзывает, но общением на татарском языке это не назвать. Иннополис – это же не только про Татарстан, сюда съезжаются люди со всей России, поэтому было бы некрасиво говорить на татарском, когда кто-то из коллег может не понимать тебя.

## КАК УСТАНОВИТЬ КЛАВИАТУРУ?

Установить русскую раскладку с татарскими буквами можно здесь – https://800147.github.io/rtu/

# “ӘБИЕМНЕҢ АЛТЫНГА ТИҢ ҮГЕТ-НӘСЫЙХӘТЛӘРЕН ҮТӘП ЯШӘРГӘ ТЫРЫШАМ”

***Дүрт ел элек якты дөньядан китеп барган Минһаҗәр абыстай Сәяхованы Самар мөселман-нары тирән гыйлемле дин әһеле, акыллы, ипле, күркәм холыклы, гадел остаз буларак беләләр иде. Ул чирек гасыр буена шәһәребездә кешеләр-гә динебез ислам дәресләрен укытты. Дини мәҗлесләрдә оста Коръән укучы, чын дәгъватчы буларак танылды.***

***Миләүшә Газимова.***



Гомере буе ислам юлыннан атлаган Минһаҗәр абыстайны бәхетле шәхес, дип атарга була, чөнки ул үзе артыннан шундый ук иманлы, дога кылучы балалар, оныклар калдырды. Аның кызлары Нәфисә, Рәйсә, улы Гомәр, оныклары – дин таләп-ләрен үтәп яшәүчеләр исемлегендә.

Без Минһаҗәр ханым Сәяхованың дүрт оны-гының берсе – 38 яшьлек Әнвәр Мәхмүтов белән әңгәмә корып, әбисеннән алган дини һәм дөньяви тәрбия турында сораштык.

***- Әнвәр, әбиеңнең нинди үгет-нәсыйхәтләрен күңелеңдә саклап яшисең?***

- Әби бездә, оныкларында, кечкенәдән исламга мәхәббәт тәрбияләде, динебезнең әһәмиятлеле-ген, Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген, Аның бөеклеген төшендереп үстерде.

Балачакта без бик еш әби белән бабайда кунак иттек. Догаларны алардан өйрәндек, намаз уку тәртибенә төшендек. Ике туган апам – әби яны-на, мин бабам янына басып, бергәләп гыйбадәт кыла идек.

Ә ял көннәрендә әбием безне үзе белән Иске мәчеткә алып бара иде. Анда без гарәп графика-сын үзләштердек.

Әби безгә кечкенә чакта гына түгел, балигъ булгач та үгет-нәсыйхәтләрен бирә иде. Эчү, тар-туның нинди начар гадәт булуын сеңдереп тәр-бияләде ул безне. Татар кызына өйләнергә кирәк-леген тәкрарлап торды.

Намаз укырга, Аллаһы Тәгаләгә шөкерана кылырга, ана телебезне онытмаска, аны саклар-га, милләтебез белән горурланырга – аның шушы сүзләре күңелем түрендә саклананалар.

Әби безгә һәрьяклап үрнәк булды. Ул үзе дә һәрвакыт мохтаҗларга, балаларга сәдака бирә иде. Безне дә шуңа өйрәтте. “Уң кулың биргән-не сул кулың күрмәсен. Хәлегездән килгәнчә ке-шеләргә ярдәм итегез, малыгызны жәлләмәгез. Биргән саен Аллаһы Тәгалә сезгә барысын да ун тапкыр арттырып кайтарачак. Сәдакалар өләше-гез”, – дип әйтә иде ул.

